...MASSA KITAPXANƏSE TƏP KITAP SAQLAY BYLEGE
ОСНОВНОЕ КНИГОХРАНИЛИЩЕ ОБЛАСТНОЙ МАССОВОЙ
им. ЛЕНИНА БИБЛИОТЕКИ АТССР г. Казань

СИШӘМБЕ
5 МАРТ
1940 ел
№ 53 (5853)
Аерым номеры 10 тиен

БАРЛЫК ИЛЛӘРНЕҢ ПРОЛЕТАРИЙЛАРЫ, БЕРЛӘШЕГЕЗ!

КЫЗЫЛ ТАТАРСТАН

ВКП(б) Өлкә Комитеты, Шәһәр Комитеты, ТАССР Верховный Советы һәм Шәһәр Советы органы.

РЕДАКЦИЯ АДРЕСЫ:
Казан, Матбугат йорты.
ТЕЛЕФОННАР: экономик бүлек 18—22, авыл хуҗалыгы һәм совет төзелеше бүлекләре 4—58, партия бүлеге һәм матбугат күзәтү бүлеге 14—75, хатлар бүлеге 21—23, культура бүлеге 18—22, информация бүлеге 5—86, төнге редакция 3—75, типография 36—60, бухгалтерия һәм игланнар бүлеге 2—19.

АШЛАМАЛАРДАН ТУЛЫСЫНЧА ҺӘМ ДӨРЕС ФАЙДАЛАНУНЫ ОЕШТЫРЫРГА

Югары иген уңышы алуны тәэмин итүдә ашламалар көчле һәм төп средстволарның берсе булып торалар. Социалистик авыл хуҗалыгы алдынгыларының тәҗрибәләре безгә моны ачык күрсәтә. Аларның рекорд иген уңышы алуга ирешүләренең нигезендә, агротехника чараларын дөрес куллану белән бер рәттән, ашламалардан киң күләмдә файдалану ята.

Ашламалардан тулысынча һәм дөрес файдалануга партиябез һәм хөкүмәтебез гаять зур игтибар бирәләр. Бу, ВКП(б) ның тарихи XVIII нче съезды карарларында бик ачык итеп чагылдырылган. Карарда болай диелә:

„Колхозларда һәм совхозларда органик һәм минераль ашламалар кулланунын дөрес системасын үзләштерергә, тиресне һәм башка төр җирле ашламаларны рациональ рәвештә саклауга һәм файдалануга аеруча игтибар бирергә, минераль ашламаларны югалтуларны бетерергә“.

Безнең Татарстан АССР колхозларында һәм совхозларында җирле ашламаларга байлык бик зур. Без тик терлекчелектән генә дә ел саен кимендә 7 миллион тонна ашлама ала алабыз. Шуның өстенә күп районнарда торф чыганаклары бар. Районнарда известь запаслары да күп. Колхозларда һәм совхозларда ел әйләнәсендә кимендә 250—300 мең тонна компост ашлама, фекали, тирес сыекчасы, көл һәм кош тизәге хәзерләргә мөмкин.

Бу ашламалардан тиешенчә файдалануны оештырган алдынгы колхозлар иген уңышын күтәрүдә һәр елны зур нәтиҗәләргә ирешәләр. Мәсәлән, үзенең уңышлары белән Татарстан АССР күләмендә генә түгел, бәлки бөтен союз күләмендә дан тоткан һәм Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә мактаулы урыннарның берсен алуга ирешкән Киров исемендәге колхоз (Әтнә районы) соңгы өч ел эчендә басуга 27 мең тонна тирес, 2.330 тонна торф, 132 тонна көл, 57 тонна кош тизәге, 600 тонна фекали керткән. Буа районының „Чулпан“ колхозында соңгы елларда булган тиресне һич тә әрәм итмичә туфракка кертеп киләләр. Колхозның тиресләнгән участкылары иген уңышын башка участкылардагыга чагыштырганда һәр гектардан 5—8 центнер артыграк бирәләр. Норлат районының „Строитель“ колхозында туфракны торф белән ашлауга бигрәк тә җидди игтибар бирелә. Бу колхозда да торфланган участкылар башка участкыларга чагыштырганда уңышны гектарыннан 4—5 центнер артыграк бирәләр. Биләр районының „Победитель“ колхозында игеннәрне тирес сыекчасы белән тукландыру нәтиҗәсендә һәр елны гектарыннан 2—2,5 центнер өстәмә уңыш алалар.

Мондый мисальләрне бик күп китерергә мөмкин.

Барлык колхозларда да үзләрендә булган ашламалар запасыннан файдалануга игтибар бирелә дип әйтеп буламы соң? Юк, кызганычка каршы, моны әйтеп булмый әле. Бик күп колхозларыбызда һәм совхозларыбызда ашламалардан файдалануга бөтенләй әһәмият бирелми. Соңгы өч елда республикабызда туфракка тирес, торф һәм көл кертү буенча планнар бары 50—60 процентка үтәлеп килде. Туфрак известьлау планы бөтенләй өзелде: план бары 10—15 процент үтәлде. Күп кенә колхозларда компост ашлама хәзерләү һәм тирес сыекчасыннан файдалану бөтенләй оештырылмаган.

Иген уңышы мәсьәләсендә, гомумән алганда, Татарстан АССР ның соңгы ике елда артка китүенең төп сәбәбе ашламалардан тулы файдаланмауга да бик нык бәйләнгән.

Хәзер республикабызның күп колхозлары йөзпотчылар хәрәкәтенә кушылдылар. Татарстан АССР, Чувашстан АССР һәм Мордовия АССР арасында төзелгән социалистик ярыш договоры буенча без быел республикабызда бөртекле культураларның һәр гектарыннан уртача 13 центнер иген уңышы алуга ирешүне йөкләмә итеп алдык. Бу йөкләмә, һич шиксез, үтәлерлек. Чөнки Татарстан уртача 13 центнер уңыш алуга ирешкән иде инде. Йөкләмә кәгазьдә генә калмасын өчен, чыннан да үтәлсен өчен, әлбәттә, җиң сызганып эшләргә кирәк булуын, иген уңышын күтәрүгә хезмәт итәрлек барлык мөмкинлекләрдән, беренче чиратта җирле ашламалардан, киң күләмдә һәм дөрес итеп файдаланырга кирәк булуын онтырга ярамый.

Быел ашламалардан файдалануга хәзерлек ничек бара соң? Турыдан - туры әйтергә кирәк: һич тә канәгатьләнерлек түгел әле. Үткән еллардагы кимчелекләр быел да кабатлана. Басуга тирес чыгару буенча еллык план һаман да әле 35,6 процент кына үтәлгән. Планны 62 процент үтәгән Питрәч, 74 процент үтәгән Биектау һәм 76,6 процент үтәгән Тымытык районнары белән бер рәттән, бу мөһим чараны үз агымына, өзелү куркынычы алдына куйган районнар да бар. Мондый районнар рәтенә планны бары 10,8 процент үтәгән Саба һәм башка күп кенә районнарны кертергә була.

Ашламаларның сыйфатына да игтибар бирү җитәрлек түгел. Басуга тирес урнына салам чыгарып күз буяучы „Казанка“ һәм „Соколка“ колхозлары (Бөгелмә районы) кебекләр, кызганычка каршы, бездә еш кына очрый әле. Калинин районының „Октябрьнең 12 еллыгы“ колхозында тиресне басуда вак өемнәрдә калдыралар, аның үсемлек өчен иң кирәкле булган маддәләренең һавага очып бетүенә юл куялар.

Җирле ашламалар туплауда һәм алардан файдалануда булган мондый кимчелекләрне кичекмәстән бетерергә кирәк. Ашламалардан файдалану буенча алдынгыларның тәҗрибәләрен барлык колхозларга җиткерүне оештырырга, бу өлкәдә агрономнардан нык эш таләп итәргә кирәк. Һәрбер колхозда һәм һәрбер совхозда тирес саклау өчен махсус урыннар булдырылырга тиеш. Бу, тирестән дөрес һәм рационал файдалануда беренче шарт булып тора.



ВКП(б) ның Казан шәһәр оешмасының V нче конференциясендә. РӘСЕМДӘ: Ленин исемендәге завод коммунистларыннан беренче рәттә (сулдан уңга)—Ф. Е. Щепетова, П. И. Дәльвин, С. А. Филиппов; икенче рәттә—А. К. Леонтьев, П. Н. Лебедева, В. И. Филинов, Р. Г. Хамидуллин һәм А. Н. Нигмәтҗанов иптәшләр. В. Лаврентьев фотосы.

ПАРТИЯНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

4 нче мартта булган иртәнге утырышта иптәш Алемасов докланы буенча фикер алышулар башланды. Беренче булып иптәш **Мельников** (ВКП(б) ның Бауман райкомы секретаре) сүз алды. Ул, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары, иптәш Сталинның күрсәтмәләре нигезендә үзләренең эшләрен үзгәртеп коруда Наркоматлар һәм совет учреждениеләре янындагы партоешмаларның кайбер уңышларга ирешүләрен күрсәтеп үтте. Шулай ук иптәш **Мельников** республика прокуратурасы, Наркомзем һәм башка кайбер Наркомат партоешмаларын каты тәнкыйть уты астына алды. Наркомзем партоешмасы Наркомат аппаратында эшләрнең торышы белән җидди рәвештә шөгыльләнмәгән. Наркомземда волокита һәм бюрократизм күренешләре әле дә яшәп килә. Узган елны Нарком тарафыннан чыгарылган 300 приказның 50 се аның үзе тарафыннан ук юкка чыгарылган.

Республика прокуратурасы работниклары совет законын тормышка ашыруда башкаларга үрнәк буласы урында, аерым хәлләрдә, алар үзләре совет законын бозалар. Мәсәлән, узган елны прокуратурага килгән жалобаларның 25 проценты билгеләнгән срокта каралмаган.

Делегат иптәш **Тышкевич** та (ВКП(б) ның Сталин райкомы секретаре) өлкә прокуратурасы һәм ТАССР Верховный суды аппаратларында волокита, бюрократизм күренешләрен, спекулянтларга, каракларга карата аларның начар көрәшүләрен каты тәнкыйть уты астына алды.

Филиппов (Ленин заводы партком секретаре), **Забродченко** (Серго Орджоникидзе заводы парткомы секретаре) иптәшләр предприятиеләр янындагы партоешмаларының администрация эшенә партиянең XVIII нче съезды карары нигезендә контрольлек итү ролен ничек үтәүләренә тукталдылар. Һәм бу эштә шәһәр комитетының аларга тиешле ярдәм күрсәтмәве турында сөйләделәр.

Делегат иптәш **Федоров** (4 нче ясалма каучук заводы партбюро секретаре) ВКП(б) Шәһәр Комитетын промышленность предприятиеләренең эше белән җитәрлек кызыксынмавы һәм предприятиеләр янындагы партоешмаларга производство мәсьәләсендә тиешле булышлык күрсәтмәве өчен каты рәвештә тәнкыйть итте.

— Безнең завод,—ди иптәш **Федоров**—күп станокта эшләүгә күчүне республикабызда беренче булып башлап җибәрде. Хәзер безнең заводта производствоның төп тармакларында эшләүчеләрнең 55 проценты күп станокта эшлиләр. Шулай ук безнең завод Союздагы ясалма каучук заводларыннан беренче булып, күп агрегатлы эшкә күчте. Шуңа күрә безнең тәҗрибәләрне уртаклашу өчен кардәш предприятиеләрдән безгә күп кенә кешеләр килделәр. Казан Шәһәр Комитеты бу мәсьәлә белән бөтенләй кызыксынмады.

Иптәш **Прокофьев** (партиянең Молотов район комитеты секретаре) коммунистларны тәрбияләүдә партҗыелышларның зур политик мәктәп булуы турында тукталды. Казан Дәүләт университеты, Врачларның Белемен Күтәрү институты, Мехкомбинат янындагы һәм башка күп кенә партоешмаларда җыелышларга хәзерлекнең яхшы булуын күрсәтеп үтте. Ә Педагогия, Ветеринария институтларында партҗыелышларның хәзерлексез үтүен кискен рәвештә тәнкыйть итте.

Тихонов (Стомотология институты директоры), **Потехин** (Врачларның Белемен Күтәрү институты директоры) иптәшләр шәһәрдә гигиена-санитария эшләренең торышы турында сөйләделәр.

— Бу елга кадәр безнең институт Союз күләмендә иң артта калган институтларның берсе булып килде. Шуңа да карамастан, Шәһәр Комитеты институтта эшләрнең торышы белән бөтенләй танышмады. Шулай ук Шәһәр Комитеты югары уку йортлары директорларының киңәшмәләрен җыю һәм тәҗрибәләрне уртаклашу эше белән дә шөгыльләнми. Безгә, яшь работникларга, мондый киңәшмәләрнең кирәге гаять зур,—ди иптәш **Тихонов.**

Иптәш **Колесников** (Н че часть) Осоавиахим һәм башка оборона оешмаларының йомшак эшләүләре, башлангыч һәм район партия оешмалары тарафыннан аларга җидди ярдәм булмавы турында сөйләде.

Күп кенә делегатлар шәһәрне төзекләндерү эшләренең начар торышына, сәүдә оешмаларының начар эшләүләренә тукталдылар һәм бу эшне яхшырту буенча кыйммәтле тәкъдимнәр бирделәр.

Конференциянең 4 нче мартта булган иртәнге утырышында фикер алышуларда барлыгы 12 кеше чыгып сөйләде.

Соңгы сәгаттә

ИТАЛИЯНЕҢ АНГЛИЯГӘ ПРОТЕСТЫ

ЛОНДОН, 4 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Римдәге хәбәрчесенең хәбәр итүенә караганда, кичә Италия хөкүмәте Германиядән Италиягә күмер ташуны блокадалауга каршы Англия илчесенә протест нотасы тапшырган.

ЛОНДОН, 4 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының хәбәр итүенә караганда, Германиядән Италиягә таш күмер китерүне туктату буенча Англиянең чараларына каршы бүген Италиянең протест нотасы иглан ителгән.

Нотада әйтелүенчә, Англия хөкүмәтенең карары Италиянең интересларына чиктән тыш һәлакәтле йогынты ясый һәм ул „халыкара хокукка каршы килә“. Аннары нейтраль илләрнең пароход йөртүләренә Англиянең контроль ясавы сугышмаучы дәүләтләрнең сәүдәсенә һәм промышленностена еш кына җидди зарар китерә диелә. Ачык диңгезләрдә почтаны тотып алу һәм корреспонденцияләргә контроль ясау чаралары Гаага конвенциясе белән гарантияләнә торган почта серен иң тупас рәвештә бозудан гыйбарәт. Нотаның ахрында әйтелгәнчә, Германия күмере Италия халкының яшәве һәм эше өчен иң кирәкле нәрсә. Шулай ук нотада, Германиядән Италиягә күмер китерүгә блокада ясау турындагы карарның „1938 нче ел 16 нчы апрель килешүе буенча Италия белән Англия арасында урнаштырылган экономик һәм политик мөнәсәбәтләрне өзүе“ әйтелә.

ВӘЗИРСТАНДА АНГЛИЧАННАРНЫҢ ҖӘЗА ЭКСПЕДИЦИЯСЕ

КАБУЛ, 3 март. (ТАСС). Һиндстанда чыга торган „Сивил энд Милитэри газет“ ының язуына караганда, Англиянең җәза экспедициясе Вәзирстандагы тау кабиләләренә каршы сугыш хәрәкәтләре башлаган. 21 нче февральдә гаскәрләр Вәзирстанның көньяк өлешендә яшәүче Әхмәтзая кабиләсенә һөҗүм иткәннәр. Бу кабилә гаскәрләргә бик нык каршылык күрсәтә.

Пәнҗабтагы ике һәм Блуҗстандагы бер пехота полкы составындагы икенче колонна, артиллерия ярдәме белән, Баннуга һөҗүм алып бара. Баш күтәрүчеләрнең нык каршылык күрсәтүләре аркасында колонна алга үтә алмаган.

Җәза экспедициясе алдына Банну һәм Кохат шәһәрләре арасында элемтә урнаштыру бурычы куелган. Бу районда сугыш халәте иглан ителгән.

Һиндстанның мөселманнар лигасы Вәзирстандагы җәза экспедициясенең хәрәкәтләренә каршы протест резолюциясе кабул иткән. Резолюциядә бу кабиләләрнең Англия колонизаторларының кысуларына түзә алмыйча баш күтәргәнлекләре әйтелә.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫНЫҢ ОПЕРАТИВ СВОДКАСЫ

3 нче мартта Карелия бугазында безнең частьләр, Выборг шәһәрен чолгап алуны дәвам иттереп, Выборгдан төньяктарак **Саарела** хуторын алдылар һәм 76 миллиметрлы 4 орудие һәм зур гаскәри берләшмә штабының җиһазландырылган узелын кулга төшерделәр. Выборгдан көньяктарак **Туппуран—Саари** атавын алып, дошманның 6 ныгытылган оборона пунктын алдылар. Шулардан 5 пункт яр буена куела торган төзек хәлдәге авыр орудиеләре булган тимер - бетоннан ясалган артиллерия корылмалары.

Фронтның башка участкыларында әһәмиятле бер нәрсә дә булмады.

Безнең авиация дошманның гаскәрләренә һәм сугыш объектларына актив хәрәкәтләр алып барды. Һавада булган сугышларда дошманның 10 самолеты бәреп төшерелде.

ВКП(б) ның Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе делегатлары игтибарына

Партиянен Татарстан өлкә оешмасының XXI нче конференциясе шушы елның 10 нчы мартында, 18 сәгаттә, Менжинский исемендәге клубта ачыла. (Казан, Карл Маркс урамы, 26).

Делегатларны теркәү һәм делегатлык билетлары бирү 8 һәм 9 нчы мартта 9 сәгаттән 23 сәгаткә кадәр һәм 10 нчы мартта 9 сәгаттән 16 сәгаткә кадәр, ВКП(б) ның Татарстан Өлкә Комитеты бинасында, 35 нче бүлмәдә булачак (Казан, Б. Красный урам, 38). Оештыру комиссиясенең телефоннары: 26—80, 13—30, яки Өлкә Комитеты коммутаторы аркылы—10.

Оештыру комиссиясе.

ЛЕНИНГРАД ХӘРБИ ОКРУГЫ ШТАБЫННАН

„СССР куллана торган сугыш методларын“ гаепләп Финляндия хөкүмәте дип аталган нәрсә тарафыннан Милләтләр Лигасына җибәрелгән һәм яңа гына чит ил матбугатында иглан ителгән „нота“ белән танышканнан соң Ленинград Хәрби Округы Штабы бу „нота“ның бөтенләе белән ачыктан-ачык ялган, фантастик раслаулардан торганлыгын күрсәтеп үтә.

1. Бу „нота“, „тыныч фин халкына каршы советның һава рейдләре көн саен диярлек ясала“ дип, „бу атакаларда йөзләрчә, ә кайчакларда 500 дән артык самолет катнаша“ дип, „совет самолетларыннан 20 мең чамасы бомба ташланган“ дип, „еш кына самолетлардан пулеметтан ату булган“ дип раслый. Шул ук вакытта „нота“, гүяки, болар барсы да башлыча тыныч халыкка каршы юнәлдерелгән дип әйтү кебек һичбер акылга сыймаслык ялган алдында да тукталып калмый. Ләкин бу „нота“ны төзүче финнәрнең никадәр тупас икәнлекләрен „нота“ның үзеннән үк күрергә мөмкин. Мәсәлән, финнәрнең „нота“да сылтау итеп алынган ачыктан-ачык арттырылган саннарына гына караганда да „һавадан бомбага тотулар вакытында тыныч халык арасыннан 392 кеше үтерелгән“. Шулай итеп, йөзләрчә, ә кайчакларда „500 дән артык“ самолет катнашы белән „көн саен диярлек“ бомбага тоту нәтиҗәсендә бөтен 3 ай эчендә, хәтта финнәрнең ачыктан-ачык күпертелгән саннары буенча да, үтерелүчеләр саны бары 392 кешегә генә җитә икән.

Бу факт үзе генә дә банкротлыкка калган Финляндия җитәкчеләренең „нота“сында совет гаскәрләренә һәм совет авиациясенә карата әйтелгән фантастик ялганнарны бөтенләй кире кага. Бу факт үзе генә дә үзенең күп санлы һәм уңышлы сугыш хәрәкәтләрендә совет авиациясенең һич тә тыныч халыкка түгел, бәлки чыннан да фин гаскәрләренә, Финляндия территориясендәге ныгытмаларга, аэродромнарга һәм башка сугыш объектларына атканлыгын тулысынча раслый. Тыныч халык арасында исә, финнәр күрсәткән саннардан ук күренгәнчә, корбаннар бик аз.

Шулай итеп, бөтен „нота“ ның Кызыл Армиягә карата яла ягу характерында булуы бөтенләй ачык һәм ул „нота“ ны төзүчеләрнең көчсез һәм ялганчы икәнлекләрен генә күрсәтә.

2. „Нота“ ны төзүчеләрнең туарылган фантазиясе шундый магнәсез раслауларга кадәр барып җитә ки, „советның коры җир частьләре Финляндия армиясенә каршы атакалар вакытында пленныйларны һәм тыныч халыкны күп тапкырлар калкан сыйфатында файдаландылар“ дип, совет гаскәрләре, гүяки, ниндидер „коматозный газ“ кулландылар һәм „шуның нәтиҗәсендә финнәрнең 11 артиллеристы авырый башлады“ дип, гүяки „СССР тарафыннан диңгездә кулланыла торган сугыш методлары да халыкара хокукка каршы килә“ дип белдерүләр ясыйлар. Бу коры белдерүләр барсы да, шулай ук „нота“ ның, гүяки, СССР сугыш алып бару кагыйдәләре турындагы 1907 нче елгы Гаага конвенциясен һәм 1929 нчы елның 27 нче июлендәге Женева конвенциясен бозды дип раслаулары да бер нәрсәгә дә нигезләнмәгәннәр һәм үзләренең җинаять эшләрендә буталып беткән Финляндия җитәкчеләренең бөтенләй ялган уйдырмалары булып торалар. Кызыл Армия шул кадәр көчле ки, ул нинди булса да агулаучы газлар куллануга мохтаҗ түгел. Кызыл Армиянең мондый газлар куллануны моральгә каршы һәм җинаят дип һәм һич сүзсез һәм гомуми күләмдә гаепләнергә тиешле дип санавы турында инде, әйтеп тә торасы юк.

Кызыл Армиягә каршы бу яла ягу уйдырмалары берсе дә Советлар Союзына каршы Финляндия җитәкчеләре авантюраларының бетүе якынлашуны ерагайта алмыйлар, шулай ук Карелия бугазындагы сугыш ныгытмаларының совет гаскәрләренә мәҗбүри рәвештә бирелүләре алдыннан өметсез эш өчен сугышырга теләмәүче фин солдатларын фин офицерларының стенага бәйләп, урында ук атулары да моңа ярдәм итә алмый.

3. Югарыда күрсәтелгән „нота“ фин ак гвардеецлары өчен туган өметсез хәлне бизәп күрсәтергә маташып, „совет гаскәрләре бары тик зур әһәмияте булмаган территорияләрне генә ала алдылар“ дип тә белдерә.

Ленинград Хәрби Округы Штабы мондый акылсыз белдерүләрне юкка чыгарып торасы да юк дип саный. Бу раслаулар Финляндия ак гвардеецларының үзләренең җиңүләре турында әле күптән түгел генә ясаган белдерүләре дәрәҗәсендә торалар һәм аларның магнәсезлеге ачык.

ПАРТИЯНЕҢ КАЗАН ШӘҺӘР ОЕШМАСЫНЫҢ V НЧЕ КОНФЕРЕНЦИЯСЕ

ВКП(б) НЫҢ КАЗАН ШӘҺӘР КОМИТЕТЫ ОТЧЕТЫННАН

Отчет чоры эчендә,—ди ВКП(б) Өлкә һәм Шәһәр Комитеты секретаре иптәш Әлемасов,—партиянең Шәһәр Комитетының эше партиянең барлык оешмаларын һәм шәһәр хезмәт ияләрен партиянең шәһәр күләмендәге IV нче һәм өлкә күләмендәге XIX нчы һәм XX нче конференцияләренең карарларын үтәүгә туплау билгесе астында, ВКП(б) нын XVIII нче тарихи съезды куйган бурычларны үтәү билгесе астында үтте. Отчет чоры, партиянең Казан оешмасының Ленинче—Сталинчы Үзәк Комитет һәм бөек Сталин тирәсенә нык тупланганлыгын, социалистик Ватаныбызның куәтен ныгыту өчен, коммунизмның җиңүе өчен киләчәктә дә көрәш алып барырга һәр вакыт хәзер торуын күрсәтте.

I. Промышленность

Сталинчыл өченче бишьеллыкның ике елы Советлар Союзының халык хуҗалыгының барлык тармакларында тагын да күтәрелү еллары булды. Өченче бишьеллык планны үтәү өчен барган бу гомуми хәрәкәттә Казан промышленносте үсте һәм үсә. 1937 нче елны 440.243 мең сумлык тулай продукция эшләп чыгарылган булса (шәһәрдәге 55 предприятие буенча), 1939 нчы елны инде продукция эшләп чыгару 539.591 мең сумлыкка кадәр, ягни 18,4 проценттан да артыграк үсте. Кайбер предприятиеләр 1939 нчы елгы планны срогыннан алда үтәделәр. Шулар арасыннан Вахитов исмендәге комбинатны, Ленин исмендәге күн заводын, Мехкомбинатын, шорный фабрикасын, язу машиналары заводын, индивидуаль кием тегү фабрикасын, эчемлек заводын һ. б. ларны күрсәтергә мөмкин. Казан пристане һәм Казан станциясе үзләренең эшләрен бер кадәр яхшыртуга ирештеләр. 1939 нчы елны соңгы 3 ел эчендә беренче тапкыр буларак промкооперация системасындагы шәһәр артельләре тулай продукция чыгару планын үтәделәр.

Сталинчыл Өченче Бишьеллык исмендәге социалистик ярышның җәелеп китүе 1939 нчы елны хезмәт җитештерүчәнлеген шактый үстерүне тәэмин итте. Бу исә эш нормаларын арттыру ягына таба яңадан карап чыгарга мөмкинлек бирде.

Ләкин әйтергә кирәк, әгәр дә артта калучы предприятиеләрнең җитәкчеләре, партиянең башлангыч оешмалары, профсоюз оешмалары, райкомнар һәм Шәһәр Комитеты үзе дә өзеклектәге фабрикаларны һәм заводларны алдынгылар сафына чыгару эше белән күбрәк шөгылләнгән булсалар промышленность өлкәсендә без тагын да зуррак нәтиҗәләргә ирешкән булыр идек. Казанда исәпкә алынган 55 предприятиедән 24 предприятие 1939 нчы елны планны үтәмәделәр. Шулардан барыннан да элек 1 нче номерлы тегү фабрикасын, саго заводын, авто-кузов заводын, „Кызыл күнче" заводын һәм башкаларны күрсәтергә була. Шушы 24 предприятие генә дә илебезгә 36.046 мең сумлык продукция биреп җиткермәделәр. Җиңел, азык һәм җирле промышленность наркоматлары системасында планны үтәү бигрәк тә начар бара.

Продукциянең үзенә төшү бәясен кимәтү урнына аны арттырган кайбер предприятиеләрнең („Строитель", җитен комбинаты, Татполиграф) җитәкчеләре мондый хәлне ни туры килсә шуның белән аңлатырга маташалар. Алар чимал кыйммәтләнүне дә, йөк ташу кыйммәтләнүне дә, ярым фабрикатның начарлыгын да сылтау итеп китерәләр, ләкин чын сәбәпләрне: чималның, ягулыкның, электр энергиясенең, материалларның, хезмәт хакы фондларының гаять дәрәҗәдә артык тотылуын һ. б. ачмыйлар. Аерым алганда, киез итек-фетр фабрикасы директоры иптәш Вязовкин шулай эшли.

Шәһәрдә промышленность төзелеше начар барды. Мәсәлән, Казпромстрой тресты 1939 нчы елгы планны 80,2 процентка гына үтәде һәм шуның өстенә 4.817 мең сум зиян китерде; 14 нче номерлы трест заданиене 93,9 процентка гына үтәде, шуның өстенә анда 3.760 мең сум зиян ясалды. Башка төзү оешмаларында да шундыйрак хәл.

Аннары иптәш Әлемасов хезмәт дисциплинасы мәсьәләләренә тулысынча тукталып, хезмәт дисциплинасын тәртипкә салу һәм ныгыту турында СССР Совнаркомы, ВКП(б) Үзәк Комитеты һәм ВЦСПС карарының күп кенә предприятиеләрдә большевикларча тормышка ашырылмавын күрсәтә. Ул гына да түгел. Производствоны таркатучылар арасында хәтта кайбер предприятиеләрнең директорлары да бар—„Спартак" комбинаты директоры Мухин, сукно фабрикасы директоры Константинов, авто-кузов заводы директоры Минкин. Алар прогулчылар итеп эшләреннән алындылар.

Планның үтәлмәве, хезмәт дисциплинасының какшаган булуы безнең партия һәм профсоюз оешмаларының партиянең XVIII нче съезды карарларын тормышка ашыру өчен әле һәр вакытта да большевикларча көрәшмәүләрен, алдынгыларның инициативасына җитәкчелек итмәүләрен, стахановчылык хәрәкәтенә начар җитәкчелек итүләрен күрсәтәләр. Ә безнең предприятиеләрдә үз эшләренә чын күңелдән бирелгән яхшы кешеләр күп.

1939 нчы елны үрнәкле эшләре өчен хөкүмәт Казандагы фабрикаларның һәм заводларның 42 стахановчысын орденнар һәм медальләр белән бүләкләде. Күп станокларга хезмәт күрсәтү—стахановчылык хәрәкәтенең яңа күтәрелеше. Ул 4 нче ясалма каучук заводы, Мехкомбинат һ. б. кебек предприятиеләрдә җәелде. Ләкин күп станокчылар хәрәкәтен куәтле төстә җәелдерү өчен әле күп эшләргә кирәк.

Партия членнарының һәм кандидатларының стахановчылар булмау фактлары әле аз түгел. Шушыннан ачык ки, шәһәрдәге барлык партия оешмалары бу тармакка җидди игтибар бирергә, барлык коммунистларның стахановчылар, алдынгылар һәм массаны оештыручылар булуларына ирешергә тиешләр. Бары тик шул вакытта гына һәм партиянең производстводагы башлангыч оешмалары администрациянең эшенә контроль ясау буенча үзләренә бирелгән хокуктан тулысынча файдаланганда гына яңа уңышларга ирешәчәк.

II. Коммуналь-торак төзелеше, сәламәтлек саклау, сәүдә

Отчет чоры эчендә партиянең шәһәр оешмасы шәһәрне төзекләндерү буенча шактый эш эшләде. 1938 нче елны төзеклек эшенә җибәрелгән акчаларның 5 миллион сумы файдаланылмыйча калган булса, 1939 нчы елны исә җибәрелгән сумалар тулысынча диярлек файдаланылды. Шәһәрне төзекләндерүгә күп кенә предприятиеләрне тарту исәбенә өстәмә рәвештә 1.700 мең сум акча тотылды. Шәһәр төзеклеге турында Шәһәр Комитеты пленумы карарларын үтәүгә Мехкомбинат директоры иптәш Барышников, „Искож" заводы директоры иптәш Медведев, 4 нче ясалма каучук заводы директоры иптәш Назаров һәм кайбер башка иптәшләр намус белән карадылар.

Иптәш Әлемасов шәһәр төзелеше эшенең көчәйгәнлеген күрсәтә торган саннар китерә.

Ләкин бу беркадәр булган алга китешне һич тә канәгатләнерлек һәм җитәрлек дип әйтеп булмый. Төзеклек турында көндәлек кайгыртучанлык күрсәтергә тиеш булган оешмалар начар эшләүләрен дәвам иттерәләр. Иптәш Әлемасов торак-көнкүреш төзелешенә, көнкүреш предприятиеләренең һәм Трампаркның эшенә тулы тукталып үтә. Горкомхозның һәм торак идарәләренең җитәкчеләре еш кына җаваплылыктан читтә калырга, үзләренең эшлексезлекләрен төрле объектив сәбәпләр белән каплап калдырырга маташалар. Бу яктан караганда мунча-кер юу урыннары тресты директоры иптәш Вәлиев бик характерлы. Ул үзенә буйсына торган учреждениеләрдә тәртип урнаштырасы урында доклад язулары яза. Төзеклек эшен безнең барлык партия оешмалары, бигрәк тә партия райкомнары, үз кулларына алырга тиешләр.

Казанда сәламәтлек саклау кирәкләренә бюджеттан акча тотуның үсүе турындагы саннар кешеләр турында, совет халкының сәламәтлеге турында Сталинча кайгыртучанлыкны ачык күрсәтәләр. 1939 нчы елны Горздрав бюджеты 22.915 мең сум булды, ә 1937 нче елны исә 15.904 мең сум гына иде. Койкалар саны артты. Шәһәрдә яңа төзелгән 5 нче больница эксплоатациягә тапшырылды. Ләкин сәламәтлек саклау өлкәсендә җидди кимчелекләр әле һаман да бик күп. Больница ярдәме күрсәтүдә генә түгел, бәлки хәтта амбулатория ярдәме күрсәтүдә дә баш тарту вакыйгаләре аз түгел. Бу хәл Молотов, Сталин һәм Ленин районнарында аеруча сизелә. Больницаларда авыруларны тәрбияләү әле һаман да начар куелган. Балалар авыруларына каршы көрәшнең канәгатләнмәслек булуы—райздравларның эшендә аеруча йомшак урын. Бу—сәламәтлек саклау учреждениеләре җитәкчеләренең үз эшләренә формаль һәм җансыз карауларының нәтиҗәсе.

Иптәш Әлемасов сәүдә эшләренең торышына игтибарны аеруча юнәлтә. Сәүдә челтәренең һәм товар әйләнешенең үсүенә карамастан, шәһәрдә сәүдә гаять түбән дәрәҗәдә тора. Сәүдә итүче оешмалар үзлегеннән сатып алып хәзерләүне начар алып баралар, сәүдә челтәренә киң куллану товарларын тартмыйлар, урлауларга һәм акча туздыруларга каршы көрәшмиләр. Партия һәм профсоюз оешмалары сәүдә мәсьәләләренә өстән караучанлык күрсәтәләр, җитәкче сәүдә кадрларын белмиләр. Шуның нәтиҗәсендә Горхлебторгның элекке директоры Чегодаевның квартирасында 100 килограмм икмәк табылу кебек фактлар килеп чыкты. Эшнең бу әһәмиятле тармагына озак вакытлар буена шушындый кеше җитәкчелек итүдә тулысынча партиянең Шәһәр Комитеты гаепле. Милиция һәм прокуратура органнары спекулянтларга каршы тиешенчә көрәшмиләр. Казан Шәһәр Советы һәм район советлары колхоз сәүдәсен оештыру өчен бер нәрсә дә эшләмиләр. Моны Шәһәр Советы башкарма комитетында базар сәүдәсен, аерым алганда колхоз сәүдәсен үстерүгә билгеләнгән 2 миллион сум акчаның файдаланылмаган булуы гына да күрсәтә.

Сәүдәдә һәм җәмагат тукланунда тәртип урнаштыру—җидди һәм зур бурыч. Партиянең бөтен оешмасы шуны хәл итүдә эшләргә тиеш.

III. Халык мәгарифе, культура һәм сәнгат

Халык мәгарифенә елдан-ел күбрәк сумалар җибәрелә. Отчет чорында Казанда 5 яңа мәктәп ачылды. Укытучылар саны 20 процентка артты. Укучылар саны 61.551 кешегә җитте. Шуның белән бергә, әйтергә кирәк, мәктәпләрнең эше әле аларга карата партия һәм хөкүмәт тарафыннан куелган таләпләргә җавап бирерлек түгел. Бер класста икенче елга калу проценты әле һаман да зур, өлгерүчәнлекне күтәрү өчен көрәш җитәрлек алып барылмый. Безнең мәктәпләребездә иң начар як—кайбер укучыларның дисциплинасызлыгыннан һәм хулиганлыгыннан гыйбарәт, ә комсомол һәм пионер оешмалары бу начарлыкка каршы чын-чынлап көрәшмиләр, укытучыга ярдәмгә килмиләр. Ул гына да түгел, комсомол оешмасының үзен педагогка каршы куюы, кайчакларда аңа дисциплинаны ныгытуда комачаулавы фактлары да бар. Молотов районындагы 84 нче мәктәптә комсомол җыелышларының күпчелеге ябык җыелыш була, хәтта коммунист укытучыны да җыелышка үзенең партия билетын күрсәткәндә генә кертkәннәр. Партия оешмалары мәктәпләрнең эшен җайга салуда үзләренең рольләрен әле хәзергә кадәр аңламаганнар.

Аннан соң иптәш Әлемасов шәһәрдәге югары уку йортларының тормышы турында сөйләүгә күчә. ВУЗ ларда өлгерүчәнлек бер кадәр яхшыруга һәм коммунистларның күпчелеге укуда алдынгылык роле уйнауга да карамастан, без әле Казан ВУЗ лары үзләренең эшләрен тулысынча үзгәртеп корганнар дип әйтә алмыйбыз. Үзләрендәге коммунистлар укуда үрнәк күрсәтми торган уку йортлары бар. Мәсәлән, Мединститутта партия членнары һәм кандидатлары арасында югары бәя алучылар 55,5 процент кына, ә институтта югары бәя алучыларның уртача проценты 61,2 процент. Марксизм-ленинизм кафедраларының да күпчелегендә эш канәгатләнерлек түгел, алар әле һаман да профессорлар—укытучылар составы белән тәэмин ителмәгән. Фәнни-тикшеренү эшләре планнары начар үтәлә. Күп кенә ВУЗ ларда студент яшьләрнең үзләрен начар тотулары фактларына каршы тиешле көрәш алып барылмый. Партиянең ВУЗ лардагы башлангыч оешмаларының һәм ВУЗ директорларының укытуның торышы өчен, укытучылар һәм студентлар арасында политик тәрбия эшенең куелышы өчен әле тулысынча җаваплылык сизмәүләрендә ВКП(б) ның Шәһәр Комитеты, Молотов һәм Бауман райкомнары гаепле.

Культура төзелеше, сәнгатне үстерү өлкәсендә партиянең Казан оешмасы һич шиксез зур уңышларга иреште. 1939 нчы елны Казанда татар операсы эшли башлауны гына әйтү дә җитә. Ләкин Казан халкына культура хезмәте күрсәтүдәге җидди кимчелекләрне дә күрми үтәргә ярамый.

IV. Совет төзелеше

Отчет чорының иң зур политик йомгакларыннан берсе Союзный һәм автономияле республикаларның Верховный Советларына һәм хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулардан гыйбарәт булды. РСФСР һәм ТАССР Верховный Советларына сайлаулар чорында шәһәрдә 224 сайлау комиссиясе оештырылды, аларда 1.606 кеше эшләде. Җирле Советларга сайлауларга хәзерлек чорында сайлау комиссияләрендә 9.615 кеше эшләде, шулардан 65 проценты партиясезләр. Масса арасында 12.000 нән артык кеше агитация алып барды.

Үткән сайлаулар Казан хезмәт ияләренең мораль-политик бердәмлекләрен һәм тупланганлыкларын, бөек Ленин—Сталин партиясе эшенә чын күңелдән бирелгәнлекләрен тагын бер кат күрсәттеләр. Сайлаучылар урналарга бердәм рәвештә килделәр, үзләренең тавышларын коммунистларның һәм партиясезләрнең Сталинчыл блогы кандидатларына бирделәр. Шәһәр Советына эшчеләрнең, интеллигенциянең һәм хезмәткәрләрнең иң яхшы вәкилләре сайланды. 490 депутаттан 348 кеше беренче тапкыр сайланган. Депутатлар арасында 29 орденлы бар, депутатларның 28 проценты югары белемле һәм 33 проценты урта белемле.

Советларның составы шундый булу сайлаучыларның шәһәрнең промышленностын, культурасын һәм төзеклеген тагын да үстерүгә юнәлдерелгән наказлары үтәләчәкнең гарантиясе. Советларга килгән яңа иптәшләр эшкә янача керештеләр. Алар актив, дисциплиналы, тапшырылган эшләргә намус белән карыйлар. Ләкин совет органнарын үзгәртеп коруның сайлаулар белән генә төгәлләнмәгәнлеген, киресенчә, аның сайлаулардан соң әле башлана гына икәнлеген истә тотарга кирәк.

V. Партия тормышы

Оборона-физкультура эшенең торышына һәм комсомол оешмаларының эшенә тулы тукталганнан соң, иптәш Әлемасов партиянең эчке тормышы мәсьәләләрен яктыртуга күчә.

Отчет чоры партиянең Казан оешмасы сафларын оешу һәм идея ягыннан тагын да ныгыту, хезмәт ияләренең киң катлау массасы белән аның элемтәләрен тагын да киңәйтү чоры булды. Партиянең шәһәр оешмасының IV нче конференциясеннән соң үткән вакыт эчендә оешма 3.916 кешегә, яки 34 процентка үсте. 1940 нчы елның 1 нче январена оешмада 7.661 ВКП(б) члены һәм 3.885 кандидат булды. Шуны да күрсәтеп үтәргә кирәк: партия сафларына кабул итүдә хатын-кызларны һәм татарларны сайлап алуга йомшак игтибар бирелде. Бу нәрсә бигрәк тә Киров һәм Ленин районнарына кагыла. Партиягә яңа кабул ителүчеләр арасында эшчеләр проценты түбән әле. Партиянең күп кенә оешмалары партиягә кабул итүдә хезмәт ияләренең барлык категорияләре өчен бердәм шартлар куелу промышленность эшчеләре арасыннан да, шулай ук алдынгы интеллигенция арасыннан да төп профессия кешеләрен партиягә бик нык сайлап алу өчен җаваплылыкны читкә какмаганлыкны, киресенчә арттырганлыкны аңламаганнар.

Партиягә кабул итүдә ВКП(б) уставын, бөек Ленин—Сталин партиясенең члены булырга теләүче һәрбер кешегә индивидуаль якын килү принципын бозулар булгалады.

Соңгы вакытта яшь коммунистлар белән эшләү беркадәр яхшырды. Бу яңа кабул ителгән күп кенә иптәшләрнең хуҗалык, совет һәм башка оешмалардагы җитәкче постларга күтәрелүләреннән генә дә күренә. Шәһәрдәге башлангыч партия оешмаларының күпчелегендә яшь коммунистлар актив эшкә тартылалар. Ләкин партия сафларына яңа кабул ителүчеләрне һичбер төрле җитәкчелексез калдыручы, аларны үстермәүче, коммунизм рухында тәрбияләмәүче оешмалар да аз түгел. 1940 нчы елның 1 нче февраленә шәһәрдә кандидатлык стажлары үткән 991 кандидат бар иде, шулардан 301 кеше кандидатлыкка 1933 нче елга кадәр үк кергәннәр. Бу һич тә нормаль булмаган хәл һәм аны иң якын арада төзәтергә кирәк.

Башлангыч оешмалар, райкомнар һәм Шәһәр Комитеты ВКП(б) ның XVIII нче съездының һәм ВКП(б) Үзәк Комитетының январь пленумының карарларын үтәп, партия членнарының язмышына шактый уйлабрак якын килә башладылар. Мәсәлән, партиянең шәһәр оешмасының IV нче конференциясеннән ВКП(б) ның XVIII нче съездына кадәр булган 11 ай эчендә партиянең Өлкә Комитеты партиядән чыгарулар турында Шәһәр Комитеты карарларының 14,6 процентын кире каккан булса, XVIII нче съездан соң чама белән шул кадәр үк чор эчендә Шәһәр Комитеты карарларының бары 3,5 проценты гына кире кагылды. Билгеле, бу сан да Шәһәр Комитетын киләчәктә партиядән чыгару мәсьәләләренә тагын да игтибар беләнрәк якын килергә мәҗбүр итәргә тиеш.

Аннары иптәш Әлемасов яла ягучыларга каршы көрәш турында, оешмада уяулыкны күтәрергә кирәклек турында сөйли. Отчет чоры эчендә 300 дән артык коммунист үзләренең партия документларын югалтканнар. Партия билетларын һәм кандидатлык карточкаларын болай массовый төстә югалту безнең сафларыбызда әле гамсезлекнең тулысынча бетерелмәгәнлеген күрсәтә. Дошманның табылган документтан җиңел файдалануы, анардан үз теләкләре өчен файдалануы мөмкинлеген әле барлык иптәшләр дә аңламыйлар күрәсең.

Партиянең шәһәр оешмасының эшендә үтәлүне тикшерү йомшак урын булып тора. Карарлар күп чыгарылалар һәм еш кына бик яхшы карарлар булалар, ләкин бөтен бәлә дә аларның үтәлүенә контрольнең начар куелган булуында.

Партиянең Шәһәр Комитеты пленумнарының һәм аппаратының эшенә тукталып, иптәш Әлемасов, соңгы вакытларда, ВКП(б) ның XVIII нче съезды карарлары уңае белән, партиянең Шәһәр Комитетының күп җитезрәк һәм оперативрак эшли башлаганлыгын аеруча күрсәтеп үтә. Барлык райкомнарда һәм шәһәр комитетында кадрлар бүлекләре төзелде. Бу, һич шиксез, кадрларны сайлап алу, урнаштыру, күтәрү һәм тәрбияләү эшен яхшыртуга ярдәм итте. Партия, совет, хуҗалык оешмаларына җитәкчелек итүгә инициативалы, Ленин — Сталин эшенә чын күңелдән бирелгән меңнәрчә яңа кешеләр килде. Бу чорда партия, совет оешмаларына җитәкчелек эшенә 800 дән артык кеше күтәрелде. Бик күп мисальләр бу яшь кадрларның җитәкчелек итә белүләрен, кыенлыкларны большевикларча җиңә белүләрен һәм уңышка ирешә белүләрен күрсәтәләр.

Ләкин әйтергә кирәк, кадрлар бүлекләре әле һаман да югары урыннарга күтәрү өчен даими ныклы резерв булдыру юлында бик аз эшләделәр. Бездә резерв булдыруга еш кына формаль төстә, кампаниячә карыйлар. Райкомнардагы һәм Шәһәр Комитетындагы кадрлар бүлекләренең җитәкчеләрендә үсеп килә торган яңа кешеләр турында җитәрлек ачык караш юк, алар кадрларны тирәнтен өйрәнмиләр һәм нәтиҗәдә югары күтәрү өчен кешеләр табу аларга еш кына кыен була. Ә андый кешеләр бар. Партия бездән кадрларны сайлап алу, урнаштыру һәм күтәрү эшенә фәнчә, дәүләтчә караш булдыруны таләп итә. Бу таләпне үтәү өчен кешеләрне өстән генә белү белән чикләнергә ярамый, работникларны тырышлык һәм мәхәббәт белән өйрәнергә, аларның тавышына колак салырга, аларга ярдәм итәргә кирәк.

Иптәш Әлемасов XVIII нче съездның тарихи карарларын, партия пропагандасының куелышы турында ВКП(б) Үзәк Комитетының 1938 нче ел 14 нче ноябрь һәм 1939 нчы ел 16 нчы август карарларын партиянең Казан оешмасының ничек үтәп килгәнлеген сөйли. Пропагандистлар, лекторлар, консультантлар кадрлары сайлап алынган, расланган һәм хәзерләнгән; шәһәрнең барлык районнарында да ВКП(б) тарихын өйрәнүчеләргә практик ярдәм күрсәтүче көтепханәләр һәм партия кабинетлары оештырылган. 1938 нчы елның 1 нче декабреннән 1940 нчы елның 1 нче январена кадәр 668 лекция укылган, аларны 119.590 кеше тыңлаган. 300 групповой консультация үткәрелгән; 4.000 нән артык кеше индивидуаль консультация алган. Хәзерге вакытта партия тарихын 30.000 нән артык кеше өйрәнә, шулардан 90 проценты үзлекләреннән өйрәнәләр.

Пропаганданы үзгәртеп коруның иң яхшы йомгакларыннан берсе шуннан гыйбарәт булды ки, күп кенә иптәшләрдә ВКП(б) тарихын өйрәнү барышында үзлекләреннән укудан тәм табу туды. Йөзләрчә коммунистлар, комсомолецлар һәм партиясез интеллигентлар инде урта звено буенча „ВКП(б) тарихының кыскача курсы"н өйрәнүне тәмам иттеләр һәм марксизм-ленинизм классиклары әсәрләрен өйрәнергә керештеләр.

Партия пропагандасының куелышында маглүм бер яхшыру барлыкны әйтү белән бергә, аның әле бездә партия таләп иткән дәрәҗәдә үсеп китә алмавын әйтергә кирәк. Мәсәлән, Ленин исмендәге заводта, җитен комбинатында, Ленин исмендәге күн заводында, Серго Орджоникидзе заводында, Кинопленкада, киез итек фабрикасында, Энергокомбинатта эшнең торышы һич тә канәгатләнерлек түгел. Болардагы партия оешмаларының җитәкчеләре кадрларны идея-политик яктан тәрбияләү мәсьәләләреннән читләшкәннәр. Өлкә Комитеты, шулай ук Шәһәр Комитеты тарафыннан күп тапкырлар күрсәтмәләр һәм искә төшерүләр булуга да карамастан, күп кенә җитәкче работниклар әле һаман да марксизм-ленинизм нигезләрен тирәнтен өйрәнүгә керешмәгәннәр. Шундый иптәшләрдән Сорвин (Наркомхоз), Ширкин (Ленин исмендәге күн заводы директоры), Вәлиев (Вахитов исмендәге җиркомбинат директоры), Афанасьев (Микоян исмендәге фабриканың директоры) һәм башка иптәшләрне күрсәтергә мөмкин.

Райкомнарның һәм Шәһәр Комитетының пропаганда һәм агитация бүлекләре, партия мәгарифе йортлары хәзергә әле канәгатләнмәслек эшлиләр. Партия пропагандасының куелышы турында Үзәк Комитет карарын матбугатыбыз йомшак үти. Дөрес, отчет чоры эчендә „Красная Татария" һәм „Кызыл Татарстан" газеталары редакцияләре үзләренең битләрендә марксизм-ленинизмны өйрәнүчеләргә ярдәмгә күп кенә материаллар урнаштырдылар, ләкин консультацияләрнең күпчелеге „кыскача курс"ның беренче бүлекләренә кагыла. Болардан тыш материалларның күпчелек өлеше үзәк газеталардан һәм журналлардан күчереп басыла. ВКП(б) тарихын үзлекләреннән өйрәнүчеләрнең, аерым пропагандистларның эш тәҗрибәләре чиктән тыш аз яктыртыла.

Иптәш Әлемасов хезмәт ияләре депутатларының җирле Советларына сайлаулардан соң халык арасында агитация эшен оныткан партия оешмаларын нык тәнкыйть итте.

Докладының соңгы өлешен иптәш Әлемасов отчет-сайлау җыелышларының һәм партиянең район конференцияләренең йомгакларына багышлый. Бу җыелышларда партиянең Казан оешмасында учетта торучы коммунистларның 79,6 проценты катнашты. Җыелышларның күпчелеге идея-политик яктан югары дәрәҗәдә үтте. Җыелышларда катнашучыларның 42,8 проценты фикер алышуларда катнашты. Җыелышларда казанышлар турында скромный гына сөйләделәр һәм кимчелекләрне нык тәнкыйть иттеләр.

Отчет - сайлау җыелышлары коммунистларның төп массасының партия һәм хөкүмәт карарларын үтәү өчен җидди төстә көрәшүләрен күрсәтте. Шуны гына әйтү дә җиттә: партия оешмаларының 71,8 процентында бюроларның һәм секретарьларның эше канәгатләнерлек дип табылды, ә үткән отчет-сайлау кампаниясендә исә бу процент бары 21,7 процент иде. Район партия конференцияләре зур эшлеклелек һәм оешканлык төсендә үттеләр. Барлык 5 райкомның политик юлы һәм практик эше канәгатләнерлек дип табылды, үткән сайлауларда исә барлык райкомнарның эшләре канәгатләнмәслек дип табылган иде.

Иптәш Әлемасов шәһәрнең партия оешмасы алдына промышленностька, шәһәр хуҗалыгына җитәкчелек итү өлкәсендә һәм партиянең эчке эше буенча күп кенә конкрет бурычлар куя.

— Шәһәр партия оешмасының бөтен көче ВКП(б) членнарының һәм кандидатларының большевистик уяулыгын һәм идея ягыннан коралланган булуларын тагын да күтәрүгә, хуҗалык һәм культура төзелешенең барлык өлкәләрендә коммунистларның авангардлык ролен тормышка ашыруга юнәлдерелергә тиеш. Һич шик юк ки, партиянең Казан шәһәр оешмасы Сталинчыл Үзәк Комитет тирәсенә, сөекле юлбашчыбыз һәм остазыбыз иптәш Сталин тирәсенә тагын да ныграк тупланыр һәм ленинизм байрагы астында алга, яңа җиңүләргә барыр. **(Көчле кул чабулар).**

ЯШЕЛЧӘЧЕЛЕК ЭШЕН ТИЕШЛЕ ЮГАРЫЛЫККА

Хезмәт ияләренең яшелчә продуктларына булган сорауларын тулысынча тәэмин итү өчен промышленность үзәкләре һәм зур шәһәрләр тирәсендә бәрәңге-яшелчә зоналары булдыру турында партиябезнең тарихи XVIII нче съезды безнең алга зур бурычлар куйды.

Татарстанда, кызганычка каршы, бу бурыч бик акрын үтәлә әле. Татнаркомзем җитәкчеләре яшелчәчелек белән шөгылләнүче совхозларда һәм колхозларда чәчү мәйданнарын киңәйтү буенча начар эшлиләр. Нәтиҗәдә, 1938 нче елдан башлап Татарстанда яшелчә чәчү мәйданы кискен рәвештә кимеде.

ССР Союзы буенча яшелчә чәчү мәйданы барлык чәчүлек мәйданының 1 процентын, ә кайбер алдынгы край һәм өлкәләрдә барлык чәчүлек мәйданының 3 процентын тәшкил итсә, Татарстанда бу бары тик 0,5 процент кына.

Шәһәр тирәсе зонасына керә торган Арча, Югары Ослан, Питрәч, Дөбъяз, Биектау, Столбище, Лаеш һәм Юдино районнарында узган ел яшелчә чәчү планы бары 82,3 процентка үтәлде. Мондый хәлне, авыл хуҗалыгының бу иң әһәмиятле тармагына җир органнарының җавапсыз караулары белән генә аңлатып була.

Чәчүлек орлык җитештерә торган мәйданнар да соңгы ике ел эчендә шактый кимегән. 1937 нче елда 200 гектар мәйданда чәчүлек орлык җитештерелгән булса, 1939 нчы елда бары 95 гектар мәйданда чәчүлек орлык җитештерелгән.

Соңгы ике ел эчендә кавын, карбыз кебек бакча культуралары үстерү буенча кайбер колхозлар уңышлы гына нәтиҗәләр бирделәр. Ширәмәт районы, „Кама“ колхозы узган ел гектарыннан 180 центнер карбыз уңышы алып, Бөтенсоюз Авыл Хуҗалыгы Күргәзмәсендә катнашу хокукын яулап алды.

Яшелчәчелекне һәм бакча культуралары үстерү эшен тиешенчә җәелдереп җибәрү парниклар хуҗалыгына һәм шулай ук теплицалар эшенә нык бәйләнгән. Шулай да парник хуҗалыгының хәзерге торышы һич тә канәгатьләнерлек түгел. Колхозларның 22 процентында гына парниклар бар. Аларның да күбесе яраксыз. Теплицалар бармак белән генә санарлык. Шәһәр тирәсендәге совхозлар тресты теплицалар төзү эшен үзенең планына да кертмәгән.

Наркомзем һәм яшелчә үстерү эше белән шөгылләнүче барлык оешмалар хезмәт ияләрен бәрәңге-яшелчә белән тулысынча тәэмин итү өчен, 1940 нчы елда яшелчәдән мул уңыш җыеп алу, аларны саклау өчен кирәк булган барлык чараларны хәзердән үк күрергә һәм бу эшкә большевистик җитәкчелекне тәэмин итәргә тиешләр.

Агроном **Вяткин.**

Арча районы, „Алан“ колхозының ефремовчы звеносы кар тоту эшендә.
А. Михайлов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Колхозара орлык алмашу өзелә

Заинский районында колхозара сортлы орлык алмашу эше начар бара. Район җир бүлеге планы буенча 17 колхозда 1.475 центнер бодай, 9 колхозда 573 центнер солы сортлыга алмаштырылырга тиеш. Ләкин бу планның райсовет башкарма комитеты тарафыннан расланганы юк әле. Нәтиҗәдә 27 нче февральгә районның бары „Кызыл Юл“ һәм „Кызыл Шәрык“ колхозлары гына сортлыга алмаштыру үткәрделәр.

(ТатТАСС).

РЕМОНТ ТӨГӘЛЛӘНМӘГӘН

Әлки районының „Комбайн“ колхозы язгы чәчүгә начар хәзерләнә. Кырга 12.878 йөк урнына бары 8.400 йөк тирес чыгарылган. 48 сабан, 18 культиватор, чәчкечләр һәм тырмалар ремонтланмаган.

„Марс“ һәм „Нептун“ колхозларында да шундый хәл. „Нептун“ колхозында тиресне авыл янына түгү фактлары бар.

Х. Ларионов.

Тракторларга ремонт ясауның барышы турында Татарстан Җир Эшләре Халык Комиссариаты сводкасы

1940 нчы елның 1 нче мартына

Көзге-кышкы ремонт планына карата процентларда

МТС лар исме	Үтәлеш	МТС лар исме	Үтәлеш	МТС лар исме	Үтәлеш
Нөркәй	100,0	Калинин	74,1	Соколка	55,6
Тымытык	100,0	Исәнбай	73,7	Тат. Ялтан	55,6
Теләче	100,0	Балтач	73,6	Кукмара	55,3
Кама Тамагы	100,0	Октябрь	73,2	Кәкре Елга	54,5
Маткавыш	100,0	Зур Кләре	72,9	Кузайкино	53,8
Актаныш	10 ,0	Мамадыш	72,2	Баулы	53,1
Мөслим	100,0	Бондюг	72,1	Дөбъяз	51,7
Янил	100,0	Әтнә	72,0	Морт	51,1
Чалпы	100,0	Тәкәнеш	71,4	Яңа Чишмә	51,1
Алга	100,0	Шөгер	68,6	Биләр	51,1
Кадрәк	100,0	Алабуга	67,3	Кызыл Йолдыз	50,9
Тирсә	100,0	Акташ	66,7	Питрәч	50,0
Т. Тамак	100,0	Норлат	65,2	Иске Письмән	48,1
Минзәлә	100,0	Кошкино	65,0	Алексеевский	47,7
Иске Чишмә	100,0	Балык Бистәсе	64,9	Ромадан	47,7
Юртыш	100,0	Ютазы	64,8	Поповка	46,9
Әлмәт	98,0	Лаеш	61,3	Салман	44,1
Черемуховский	97,6	Зирекле	63,5	Константиновка	43,7
Кызыл Чапчак	94,0	Кичү	63,0	Әлки	42,0
Беренче Май	92,7	Чүрибураш	62,3	Рождественский	41,5
Азин	92,3	Каргалы	62,5	Зәй	41,2
Сарман	89,7	Мөслим (Чистай)	62,5	Мөрәле	41,1
Ишн	88,2	Трехозерский	62,0	Карамалы	40,8
Чыбыклы	86,5	Мәйлан	61,3	Тельман	40,0
Буденный	85,5	Б. Матак	61,1	Димитровский	36,1
Дәүләки	85,0	Кузнечиха	61,1	Зөя	33,3
Аксубай	83,3	Иске Тимошкино	61,0	Үзәк	31,6
Мәлки	83,3	Чүпрәле	61,0	Чокалы	29,1
Тархан	81,4	Макыл	60,8	Татходяш	27,7
Зур Поляна	81,0	Биектау	60,4		
Столбище	80,0	Бөгелмә	60,3		
Чаллы	79,2	Арча	57,1	МТС лар буенча	
Куйбышев	78,0	Юдино	57,4	барлыгы	67,5
Тәтеш	76,9	Чиябаш	56,9	1940 нчы елның	
Чишмә	76,6	Әхмәмәт	56,8	25 нче февраленә	63,8
Саба	75,0	Кызыл Юл	55,9	1939 нчы елның	
Чистай	75,0	Буа	55,8	1 нче мартына	69,5

ЧИТ ИЛЛӘРДӘ

КӨНБАТЫШ ЕВРОПА СУГЫШЫ

ПАРИЖ, 3 март. Сугыш хәрәкәтләре турында кичә кич Парижда иглан ителгән белдерүдә болай диелә: „Мозельдән көнчыгыштарак разведка отряды немецләрнең күп санлы отряды белән очрашкан. Бу соңгысы аңа һөҗүм иткән. Ике арада сугыш башланган һәм дошман югалтуларга дучар ителгән. Швейцария чигеннән Ардени районына кадәр бөтен фронтта авиациянең активлыгы үсә“.

Бүген иртә белән Парижда иглан ителгән белдерүдә болай диелә: „Алгы отрядларның гадәттәге хәрәкәтләре булды. Франциянең һава разведкасы Германиягә бик тирән үтеп керде. 2 нче мартта Франциянең истребитель авиациясе безнең позицияләребез турысында дошманның 2 разведка самолетын бәреп төшерде. Безнең самолетлар барсы да үз базаларына кайттылар“.

БЕРЛИН, 3 март. Германия армиясенең верховный командованиесе хәбәр итә: „Көнбатыш фронтта артык әйтерлек вакыйгалар юк. Германия авиациясе көне буе Төньяк диңгез өстендә разведка очышлары ясады. Англиянең көнчыгыш яры якынында 2 сакчы карабка һәм коралланган 11 сәүдә пароходына һөҗүм ясалды. Аларның бер өлеше батырылды, бер өлеше бик нык зарарланды. Германия самолетлары төньяк-көнчыгыш Франция өстендә, Париж районында разведка очышлары үткәрделәр. Франция—Германия чигендә патруль очышлары вактында һава сугышлары булды. Нәтиҗәдә Франциянең 3 самолеты бәреп төшерелде. Германиянең 2 самолеты үзләренең базаларына кайтмадылар“.

КОММУНИСТИК ГАЗЕТА ТИПОГРАФИЯСЕНДӘ ШАРТЛАУ

СТОКҺОЛЬМ, 3 март. (ТАСС). Швециянең Лулео шәһәрендә чыга торган „Норшенсфламман“ исемле коммунистик газетаның типографиясендә бүген төнлә шартлау булды. Берничә минут эчендә бөтен бина гаят зур ялкын белән чолгап алынды.

Бинада газета редакциясе, шулай ук аның сотрудникларының квартиралары урнашкан иде.

Издательствоның директоры, Швеция коммунистлар партиясе Үзәк Комитетының члены Артур Хельберг, аның хатыны һәм кеченә кызы янып үлделәр. Шулай ук бер хатын һәм аның 10 яшлек кызы һәлак булды. Газета редакторы—компартия җитәкчеләреннән берсе—Филипп Форсберг бик нык яраланды.

Бик соңга калып килгән янгынчылар командасы күршедәге биналарны саклау белән генә чикләнде. Шартлауны Англия-Франция сугыш уты кабызучыларының агентларына каршы көрәшүче Швеция компартиясен һәр вакыт эзәрлекләүче реакционерлар оештыргандыр дип уйлыйлар.

Һиндстандагы хәл турында Англия матбугаты

ЛОНДОН, 2 март. (ТАСС). Һиндстан милли конгрессы башкарма комитеты бюросының соңгы резолюциясе турында Англия матбугаты зур курку белән яза. Резолюциядә болай диелгән иде: „Британия империализмы кулында булганда Һиндстанга азатлык тәэмин ителмәячәк. Һинд халкы үз конституциясен бары тик үзе генә төзи ала һәм дөньядагы башка илләр белән мөнасәбәтләр турындагы мәсьәләне ул гомуми сайлау хокукы нигезендә сайланган учредительный собраниедә хәл итә алачак“.

„Ньюс кроникл“, бу карарны аңлатып, болай дип яза: „Бу сугышта союзникларның эшенә Һиндстанның үзенең бәйсезлеге өчен восстание күтәрүе һәм аны көчләп бастыру күрнеше китергән кадәр зарарны башка бер нәрсә дә китерә алмас иде“.

ГАНДИНЫҢ БЕЛДЕРҮЕ

ЛОНДОН, 3 март. (ТАСС). Рейтер агентлыгының Калькуттадагы хәбәрчесе белән сөйләшкәндә Ганди Һиндстан милли конгрессының Һиндстанга азатлык бирелми торып тынычланмаячагын белдергән. Аннары Ганди конгресcның Һиндстан һәм Бирма эшләре буенча министр Зетлэнд куйган шартларда сөйләшүләр алып бара алмавын әйткән. Һиндстан сугышта катнаша алмый. Икенче төрле итеп әйткәндә, конгресс Англиягә мораль булышлык күрсәтә алмый. Мәсьәлә конгресска түгел, бәлки Англиягә бәйләнгән.

Гитлерның Уэллесны кабул итүе турында Ассошиэйтед Пресс агентлыгы

НЬЮ-ЙОРК, 3 март. (ТАСС). Ассошиэйтед Пресс агентлыгының Берлиндәге хәбәрчесенең язуына караганда, Уэллес сәгат ярым буена Гитлер белән сөйләшкән. Сөйләшү вактында Американың Берлиндәге ышанычлысы Керк, шулай ук Риббентроп, Гитлер канцеляриясенең начальнигы Мейсснер һәм тәрҗемәче Шмидт булганнар. Хәбәрченең язуынча, Гитлер Уэллеска Германия—Совет килешүләренең Германияне Англиягә һәм Франциягә каршы сугышта экономик яктан җиңелмәслек икәнлекләрен әйткән. Гитлер, барлык Америка илләренә карата АКШ нинди йөкләмәләр алган булса, Германия дә Үзәк Европада үз өстенә шундый ук йөкләмәләр алды дигән. Германия үзенең колонияләрен кайтаруны тели. Коралсызлану мәсьәләсенә кагылып, Гитлер, диңгез юлларына Англиянең контролен булдырмау өчен Англиянең Гибралтар, Мальта, Сингапур кебек крепостларын коралсызландыруны таләп иткән. Гитлер Уэллестан, әгәр дә Панама каналына Америкадан башка держава контрольлек итсә, АКШ ның позициясе нинди булыр иде дип сораган. Аннан соң Гитлер Германиянең Богемия, Моравия, Словакия, Польша һәм Венгрия өстеннән һәр вакыт гегемон булып торуын, шулай ук Англиянең һәм Франциянең Балкан һәм Скандинавия илләрен Германиягә каршы котыртмаячакларына гарантия бирелүне таләп иткән. Гитлер Уэллестан, әгәр дә Азиядәге яки Европадагы берәр держава Мексикага кагыла калса АКШ нинди позиция алыр иде дип сораган.

КЫТАЙДА СУГЫШ ХӘРӘКӘТЛӘРЕ

(ТАСС хәбәрләреннән)

КӨНЬЯК КЫТАЙДА

Гуанси провинциясенең көньяк өлешендәге фронтта Наньнин—Биньян юлында сугышлар дәвам итә. Шулай ук Наньниннан көньяк-көнчыгышта да каты сугышлар бара. Сяодун районында кытайлар япон гаскәрләренең атакаларын кире кактылар.

Кытай гаскәрләре Сватоудан төньяктарак Дэнхайны алганнан соң алга баруларында дәвам итәләр. Кытайлар 100 дән артык винтовка кулга төшерделәр. Чаочжоу тирәләрендә сугышлар бара.

Моннан берничә көн элек курчак власть гаскәрләренең бер отряды Кантоннан көньяктарак Шуньдэ районында хәрәкәт итүче кытай гаскәрләре ягына чыкты.

ҮЗӘК КЫТАЙДА

Алынган хәбәрләргә караганда, күптән түгел Чжецзян провинциясендә Сяошань районында булган сугышлар вактында японнар зур югалтуларга дучар булганнар. Кытай хәбәрләренә караганда, Сяошаньнан Ханчжоуга японнарның үтерелгән солдатлары һәм офицерлары төялгән 12 йөк автомобиле җибәрелгән.

ТӨНЬЯК КЫТАЙДА

Шаньси провинциясенең көньяк-көнбатыш өлешендә Датун—Пучжоу тимер юлының көньяк тармагы районында сугышлар бара.

Бэйпин һәм Тяньцзин районнарында, шулай ук Шаньдун провинциясендә дә бик көчле сугышлар бара. Бу районнарда японнарның кытай партизаннарына каршы җибәрелгән җәза отрядлары кытайларның көчле каршылыгына очрыйлар.

8 нче МАРТ *)

КЛАВДИЯ НИКОЛАЕВА

Сталинчыл өченче бишьеллык план. куйган бурычлар социалистик ярышның һәм стахановчылык хәрәкәтенең яңа күтәрелешен тудырдылар. Халык хуҗалыгы тормышының күп тармакларында хатын-кызлар социалистик ярышны башлап җибәрәләр һәм алдынгы көрәшчеләр сыйфатында меңнәрчә кешеләрне ияртеп баралар.

Социалистик ярышның бу яңа күтәрелешендә иң әһәмиятлесе—күп станокларда эшләүгә күчү һәм берничә профессияне үзләштерү.

Югары хезмәт җитештерүчәнлеге өчен, өченче бишьеллык заданиеләрен срогыннан алда үтәү өчен хәрәкәттә хатын-кызлар бик яхшы үрнәкләр күрсәтәләр.

Ногин исемендәге фабрика тукучысы Екатерина Ивановна Подсобляева 284 станокта эшли. 1939 нчы елның беренче яртысында ул планнан тыш 53.421 метр мануфактура эшләп, планны 105,45 процент итеп үтәде. Иптәш Подсобляева Ленин ордены белән бүләкләнде.

Л. М Каганович исемендәге 1 нче Дәүләт шарикоподшипниклар заводының роликлар цехында эшләүче иптәш Овчинникова 3 станок урнына 7 станокта эшли, планны 150 процент итеп үти.

Хатын-кызларның тимер юл транспортындагы хәрәкәтләре аеруча әһәмиятле. Машинист Зинаида Троицкая инициативасы буенча 1938 нче елны ук инде Ленин тимер юлының Москва—Сортировочная депосында хатын-кызлардан беренче паровоз бригадасы оештырылган иде.

1939 нчы елның икенче яртысында инде Советлар Союзының тимер юлларында хатын-кызлардан 48 кеше паровоз машинисты һәм 4.500 кеше машинист ярдәмчесе булып эшләделәр. 23 меңнән артык хатын-кыз төрле тимер юл белгечлекләре буенча курсларны тәмам итеп чыктылар.

Сортировочная депосы машинистының хатыны, 4 бала анасы Антонина Георгиевна Чупакова элек йорт хозяйкасы иде. Ул бик нык күңел биреп укырга башлады. Алты айлык курсны тәмам иткәч иптәш Чупакова паровоз машинисты ярдәмчесе булып эшли башлады. Транспортта үрнәк булырлык итеп эшләгән өчен хөкүмәт иптәш Чупакованы „Почет билгесе“ ордены белән бүләкләде.

Алдынгы совет хатын-кызлары инициативасы белән патриот хатын-кызлар арасында ирләренең һәм ир туганнарының производстводагы эшләренә ярдәм итү һәм әгәр кирәк булса станокларда һәм агрегатларда эшче ирләрне алмаштыру омтылышы туды.

Людмила Подсевалова һәм Татьяна Ипполитова иптәшләр Магнитогорскийның Сталин исемендәге заводында курсларда укып чыктылар һәм хәзер иптәш Подсевалова машинист ярдәмчесе булып, иптәш Ипполитова корыч коючы ярдәмчесе булып эшли. Кызлардан 16 кеше, иптәш Подсеваловадан үрнәк алып, хәзер машинист ярдәмчесе булып эшлиләр.

Дзержинский исемендәге металлургия заводына эшчеләрнең хатыннарыннан 400 кеше, Ворошиловградтагы паровоз заводына 1.500 йорт хозяйкасы эшкә керде.

Шахталарда да йорт хозяйкалары хәрәкәте киң күләмдә җәелде, анда хатын-кызлар иң катлаулы профессияләрне үзләштерә башладылар.

Колхоз төзелеше крестьян хатын-кызларын азат итү буенча 1917 нче елның октябрендә башланган эшне төгәлләде. Ленин—Сталин партиясе җитәкчелегендә колхозлар хатын-кызларны политик, культуралы һәм таза тормышның киң юлына алып чыктылар. Колхоз төзелеше крестьян хатын-кызларына үзләренең сәләтләрен һәм талантларын җәелдерергә тулы мөмкинлек бирде. Алар—ударниклар һәм стахановчылар, актив дәүләт эшлеклеләре. Йөз меңнәрчә хатын-кызлар авыл, район һәм өлкә советларында эшлиләр; йөз меңнәрчә хатын-кызлар колхоз правлениеләренең председательләре һәм членнары, звено җитәкчеләре һәм бригадирлар булып эшлиләр; хатын-кызлардан 32 мең кеше тракторчылар булып, 8 меңнән артык кеше комбайнчылар булып һәм 16 мең кеше комбайнчыларның ярдәмчеләре булып эшлиләр. Колхозчы хатын-кызлар иптәш Сталинның „...бары тик колхозда гына алар ирләр белән бер тигез булып әверелү мөмкинлегенә ия булалар. Колхозлардан башка—тигезсезлек, колхозларда—хокуклар тигезлеге“ дигән сүзләрен яхшы хәтерлиләр.

Совет халкының мактанычы булган Демченко, Гнатенко, Ковардак һәм Ангелина артыннан янадан меңнәрчә һәм меңнәрчә хатын-кызлар—социалистик игенчелек һәм терлекчелек алдынгылары күтәрелде.

Колхоз төзелеше миллионнарча хатын-кызларны яңа, шатлыклы тормышка күтәрде. Үзбәкстанның, Казагстанның, Кара Калпагстанның, Таҗикстанның, Төркмәнстанның, Азәрбәйҗанның мамыкчы колхозчы хатын-кызлары иске нормаларны җимерделәр һәм капиталистик илләрнең һичберсе белми торган уңышлар алуга ирештеләр.

Царизм вактында милли окраиннардагы изелгән хатын-кызлар чадраларын һәм пәрәнҗәләрен ташлыйлар. Алар хуҗалык, культура эшенең төрле тармакларына кыю рәвештә күтәреләләр.

Совет хатын-кызларына мәктәпләрнең, төрле курсларның, техникумнарның, югары уку йортларының ишекләре киң ачылган.

Ир балалар өчен булган кебек, кыз балалар өчен дә гомуми уку мәҗбүри. Закавказьедә, Урта Азиядә укучы кыз балаларның саны арту аеруча күзгә бәрелә. Царизм вактында анда кыз балаларны бөтенләй укытмадылар һәм хатын-кызлар анда бөтенләй укыйяза белмиләр иде. Ә хәзер безнең хатын-кызлар арасында инженерлар, техниклар, врачлар, агрономнар, укытучылар, фәнни работниклар, музыкантлар, артистлар, скульпторлар бар. Алар безнең героик эпохабызга лаеклы гүзәл иҗад үрнәкләре бирәләр.

Безнең илдә аналар даими кайгыртучанлык һәм игтибар белән чолгап алынганнар. Партиябез һәм хөкүмәтебез аналарның бәхетле һәм шат булулары тәэмин итү өчен бөтен нәрсәне эшлиләр. Безнең дәүләтебез күп балалы аналарга инде 3 миллиард сумнан артык акча бирде. Балалар яслеләренең һәм балалар бакчаларының, пионер лагерьларының, площадкаларның һәм башкаларның саны елдан-ел үсә бара.

Һәрбер совет гражданины—һәрбер ир һәм хатын-кыз—үзенең гүзәл Ватанын саклауга хәзер торырга тели һәм хәрби эшне үзенең якын эше итеп саный. Гомуми хәрби хезмәт турындагы яңа закон хатын-кызларга Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе сафларында булу хокукын бирә. Бу закон миллионнарча хатын-кызлар массасының патриотлык күтәрелеше белән каршы алынды. Иптәш Ворошилов болай диде:

...„Совет хатын-кызлары, шул исәптән Кызыл Армиядәге хатын-кызлар, ирләр белән берлектә, социалистик Ватаныбыз алга китсен, ныгысын, социалистик җиңүләребезнең һәм казанышларыбызның барлык чәчәкләре белән чәчәк атсын өчен, бөтен нәрсәне эшлиләр. Алар бөтен дөньяда тынычлык булу ягында торалар, алар хезмәт иясе кешелек дөньясының бәхете өчен көрәшәләр.

Әгәр дә сыйнфи дошманнар үзләренең юлбасарлык уйларын тормышка ашырырга һәм Советлар Союзына һөҗүм итәргә маташсалар, җиңелмәслек Кызыл Армиябез белән бер рәттән, хатын-кызларыбыз йөзендә, совет аналары, хатыннары һәм кыз туганнары йөзендә алар бөтен нәрсәне җимерүче көчне очратачаклар“.

Безнең хатын-кызлар җиңүләрнең үз-үзеннән килмәвен, аларны яулап алырга кирәклекне бик нык хәтерлиләр. Социализм дошманнарына каршы рәхимсез көрәштә безнең халкыбыз Бөек Октябрь Социалистик революциясенең казанышларын саклап калды.

Безнең данлыклы Эшче-Крестьян Кызыл Армиясе гражданнар сугышында, Хасан күле янындагы көрәштә, Монголия Халык Республикасы чикләрен саклауда, Көнбатыш Украина һәм Көнбатыш Белоруссия халыкларын азат итүдә үзен бетмәс-төкәнмәс данга күмде. Хәзер ул, сугыш плацдармын бетерү, СССР ның хәрби куәтен ныгыту, аның төньяк-көнбатыш чикләрен, революциянең бишеге булган Ленин шәһәрен саклау белән бергә, фин халкын алпавытлардан һәм капиталистлардан азат итүдә Финляндиянең Халык Хөкүмәтенә ярдәм күрсәтә. Бу көрәштә безнең хатын-кызлар да геройларча катнашалар. Алардан күбесенең исемнәре безнең Советлар Союзына билгеле. Алар арасында Ленин ордены белән бүләкләнгән хәрби фельдшер В. И. Титкова, „Кызыл Йолдыз“ ордены белән бүләкләнгән 3 нче ранг хәрби врач Р. З. Иоффе, „Кызыл Йолдыз“ ордены белән бүләкләнгән 1 нче ранг хәрби врач Г. Л. Розенбаум һәм башка бик күпләр бар.

Илебездәге хатын-кызларның йөрәкләрендә социализм дошманнарына, сугыш уты кабызучыларга һәм провокаторларга карата зур дошманлык хисе кайный. Безнең чикләребезгә кул сузарга батырлык итүчеләрнең барсын да җир йөзеннән себереп ташлау өчен, миллионнарча хатын-кызлар партиянең, хөкүмәтнең, иптәш Сталинның беренче чакыруы белән оешкан рәвештә күтәреләчәк икәнлеген дошманнар белеп торсыннар.

Совет хатын-кызлары капиталистик илләрдәге хезмәт иясе хатын-кызларның революцион көрәшләрен зур игтибар белән күзәтеп баралар. СССР хатын-кызлары хәл иткеч сугышларда капиталистик илләрдәге хезмәт иясе хатын-кызлар массасының мактаулы урын алачагын бик яхшы беләләр. Испаниядә хатын-кызларның героик көрәше үз үзенне аямауның күп кенә үрнәкләрен күрсәтте. Кытай хатын-кызларының көрәше аларның геройлыкларын һәм батырлыкларын күрсәтә.

Коммунистик интернационалның „Барлык илләрнең пролетарийлары, берләшегез!“ дигән чакыруы көннән-көн көчлерәк һәм куәтлерәк булып яңгырый. Ул бөтен дөньядагы хезмәт иясе хатын-кызларны, коммунизм өчен, бәхетле һәм шатлыклы тормыш өчен көрәшкә, Маркс—Энгельс—Ленин—Сталин байрагы астында үз көчләрен оештырырга һәм тупларга чакыра.

*) Ахры. Башы кичәге номерда.

Пехота училищесе һәм аның кешеләре

1919 нчы елның 23 нче февралендә Казан хәрби пехота училищесе төзелде. Үзенең XXI ел яшәү дәверендә училище Кызыл Армия өчен Ватаныбызның ялкынлы яш патриотларыннан күп санда яхшы хәзерлекле командирлар хәзерләп чыгарды.

Гражданнар сугышы елларында училище курсантлары фронтка китеп үз-үзләрен аямыйча Ватаныбызны интервентлардан батырларча сакладылар. Училищене тәмам иткән күп кенә иптәшләр Кызыл Армиябезнең данлыклы тарихын гүзәл сәхифәләр белән тулыландырдылар. Шушындыйлардан Стояльников, Базаров, Курицин, Луданов һ. б. күрсәтергә була. Алар Совет хөкүмәте тарафыннан бөек бүләк—СССР орденнары белән бүләкләнделәр.

Безнең училище тәрбияләп үстергән кешеләр Хасан күле районында һәм Халхин-Гол елгасы янында булган сугышларда, Көнбатыш Украинадагы һәм Көнбатыш Белоруссиядәге туганнарыбызны азат итү походында батырлыкның иң яхшы үрнәкләрен күрсәттеләр. Лейтенантлардан Галимов, Садыйков, Харисов, Хәбибрахманов, Шабашов, Боровик, Хасанов, Чекалов, Волков, Надуткин һәм башка күпләр үзләренә йөкләнгән бурычларны батырларча үтәделәр. Алар үзләренең геройлыклары өчен орденнар белән бүләкләнделәр.

Финляндия хезмәт ияләрен азат итү өчен Маннергейм бандасына, ак финнәргә каршы сугышта да, аларны тар-мар итүдә дә безнең училищене тәмам иткән лейтенантлар үзләрен сынатмыйлар. Алар батырлыкның югары үрнәкләрен күрсәтәләр. Менә аларның берсе яш лейтенант иптәш Александр Тур. Ул үзенең ротасы белән генә дә Маннергейм бандасының батальонын тар-мар итте.

Югарыда исемнәре күрсәтелгән иптәшләр безнең училищенең бөек мактанычы булып торалар. Безнең яш курсантларыбыз алардан үрнәк алалар һәм алар кебек булырга омтылалар.

Әгәр дошман безнең изге чикләребезгә үзенең пычрак кулын тидерергә батырчылык итсә, пехота училищесенең курсантлары, командирлары дошманны үз җирендә тар-мар итәргә Кызыл Армиябез белән берлектә һәр вакыт хәзер торалар. Алар Ватан өчен, коммунизм эше өчен, Ленин—Сталин партиясе эше өчен батырлыкның яңадан-яңа үрнәкләрен күрсәтергә хәзер торалар.

Г. Низам.

8 нче МАРТ КӨНЕ АЛДЫННАН

ЗАВОД КЫЗЛАРЫ

Чистай шәһәренең судноларга ремонт ясау заводында хатын-кызлардан барлыгы 140 кеше эшли.

Әлек рядовой, ярдәмче эшләрдә эшләгән күп кенә кызлар хәзер заводның атаклы стахановчылары, мастерлар һәм цех начальниклары.

Менә иптәш Людмила Васина. Заводка эшкә килгәндә ул бик яш иде әле. Шуңа карамастан, үзенә тапшырылган эшне сөеп, тырышып эшләве нәтиҗәсендә берике ел эчендә бөтен завод коллективына билгеле һәм атаклы стахановчы булып танылды. Атаклы стахановчы булу, техниканы отличного үзләштерү һәм үзендә тупланган бай тәҗрибәне башкалар белән уртаклашу—иптәш Васина алдында торган мөһим бурычлар әнә шулар иде. Ул бу бурычларны үтәү турында уйлап кына калмады, бәлки сокланырлык иҗади хезмәт, тырышлык һәм күтәренке дәрт белән практикада күрсәтте. Ул шушы заводта комсомолга һәм ВКП(б) сафларына керде. Эшчеләр коллективы хезмәт житештерүчәнлегенең яңадан-яңа уңышларын яулап алучы, намуслы хезмәт белән күпләргә үрнәк күрсәтүче, сәләтле Людмила иптәш Васинаны район советына депутат итеп сайлады. Ул хәзер заводта электромонтаж цехының атаклы мастеры булып эшли. Аның инициативасы һәм тырышлыгы белән цехның барлык эшчеләре стахановчылар булып әверелделәр. Үз нормаларын әледән-әле арттырып үтәүче, югары сыйфатлы продукция бирүче хатын-кызлар хәзер заводта күпләп саналалар. Алар хезмәт житештерүчәнлеген күтәрүнең яңа үрнәкләрен бирәләр.

Бу заводның обой цехында күп еллар буена ударниклар һәм соңгы ике-өч ел эчендә стахановчылар булып эшләүче Филатова, Иванова, Колесова иптәшләр сокланырлык гүзәл эш үрнәкләре күрсәтәләр.

Иптәш Филатова 1939 нчы елның декабрь планын 430 процент, иптәш Иванова—265 процент, иптәш Колесова—207 процент итеп үтәделәр, ә 1940 нчы елның январь ае планын алар 250—300 процент итеп үтәделәр. Алар Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне—8 нче Мартны производствода яңадан-яңа уңышлар белән каршылау турында йөкләмә алдылар.

Такта яру цехының стахановчы хатын-кызлары Наумова, Уралова, Королева һәм Медведева иптәшләр намус белән эшлиләр. Алар 8 нче Мартны зур күтәренкелек һәм производстводагы активлык белән каршылау өчен көрәшәләр.

К. Исламов.

Медицина институты студентлары мотоциклны өйрәнәләр. РӘСЕМДӘ: уку отличницасы, комсомолка Нина Узлова. Ул 8 нче мартка мотоциклда йөрергә өйрәнүне тәмамлый һәм аны йөртү хокукын алачак.

А. Попов фотосы (ТатТАСС фотохроникасы).

Тагын килегез!

27 нче февральдә татар совет язучыларыннан бер төркем киез итек-фетр техникумы һәм күн техникумы студентлары белән очрашты.

Юлбашчыларның һәм язучыларның рәсемнәре белән бизәлгән зал шыгырым тулган. Студентлар зур тынлык эчендә Газый Кашаф иптәшнең татар совет әдәбияты турындагы кереш сүзен тыңлыйлар.

30 ел буена татар әдәбиятында армыйталмый эшләп килүче язучы Шәриф Камалны студентлар көчле алкышлар белән каршыладылар. Ул газаплы иске тормышның язучыларны ничек изгәнлеген сөйләде. Хәзерге бәхетле тормышыбызда художник өчен һәм гомумән барлык хезмәт ияләре өчен бөтен мөмкинлекләр барлыкны күрсәтеп үтте. Шәриф Камал үзенең иҗад эшенә кагылып „Матур туганда“ романының икенче кисәген язып бетергәнлеген белдерде. Көчле алкышлар укучыларның бу әсәрне өзелеп көтүләрен һәм язучының уңышлы эше өчен шатлануларын бик ачык күрсәтәләр.

Очрашу кичәсендә татар совет язучыларыннан тагын Ф. Бурнаш, С. Хәким, А. Шамов, Х. Туфан, М. Әмир һ. б. иптәшләр катнаштылар. Укылган хикәяләрне, сөйләнгән шигырьләрне студентлар бик яратып тыңладылар.

Шул ук техникум укытучысы Кучербаев һәм студент М. Гаязов үзләренең шигырьләрен укыдылар. Бу иптәшләрнең каләмнәре өметле генә күренә, үз иҗадлары өстендә ныклы эшләсәләр алардан киләчәктә яхшы әсәрләр көтәргә кирәк.

Техникум житәкчеләре бу очрашуга зур әһәмият биргәннәр һәм кичәне матур итеп оештыра белгәннәр. Башка уку йортлары аларның бу эшеннән үрнәк алырлар дип уйлыйбыз.

Кичә язучыларда көчле тәэсир калдырды, аларда иҗад эшенә тагын да зур дәрт тудырды. Язучыларны озаткан чакта студентлар: „Тагын килегез!“—дип калдылар.

А.

ШАХМАТ—ШАШКА

Левенфиш—Алаторцев

СССР гроссмейстеры Левенфиш белән мастер Алаторцев арасында Москвада шахмат буенча бара торган ярышны Казан шахматчылары зур кызыксыну белән күзәтәләр. Бу ярышның барлык партияләре өйрәнелә, уенның техникасы, яңа вариантлар турында үзеннән-үзе беседалар башланып китә.

„Зенит“ спорт җәмгыяте тарафыннан оештырылган бу ярыш 14 партиядән уйнала. Алаторцев ярышны отса яки ничья белән бетерсә, ягъни ярыш нәтиҗәсендә очколар саны бер тигез булса, ул вакытта аңа СССР гроссмейстеры дигән исем биреләчәк.

29 нчы февральдә Москваның Союзлар Йортында ярышның 7 нче партиясе уйналды. Шуның белән ярышның беренче яртысы тәмам булды. Москва газеталарының хәбәр итүенә караганда, 7 нче партиядә каралар белән уйнаган Алаторцев бик яхшы позициягә ирешеп, үзенең өстенлеген йөреш саен ныгыта барган. Гроссмейстерның отылуы һич шиксез дип торганда, Левенфиш үзенең атын биреп кискен комбинация ясый. Йөрешләрне уйларга бик аз вакты калган Алаторцев дөрес саклану юлын таба алмыйча 39 нчы йөрештә бирелергә мәҗбүр була.

Бу партияне оту белән Левенфиш үзенә шактый зур өстенлекне тәэмин итте. Ярышның беренче яртысыннан соң Левенфишнең 4,5, Алаторцевның 2,5 очкосы бар.

Г.

Казан чемпионаты

Казан беренчелеге өчен шахмат турнирының 8 нче турында Нәҗметдинев белән Сайгинның очрашуы игътибар үзәгендә булды. Сайгин Нәҗметдиневтән нак бер очкога алда бара. Ул бу партияне дә оттырмау өчен үзенең бөтен көчен куйды.

Шахмат уены дебютларга, вариантларга гаять бай уен. Ул вариантларның бик күчеләре һәм нык өйрәнелеп инде искерә төшкәннәре, турнирларда бик аз кулланыла торганнары бар. Нәҗметдинев Сайгинга каршы нак әнә шундый вариантны уйнады. Вена партиясе дип йөртелә торган дебютта Нәҗметдинев кулланган вариант өстән караганда акларга ниндидер өстенлек бирә шикелле булып күренә. Ләкин, асылда, каралар позиция ягыннан ныклы басым алалар һәм нәтиҗәдә аклар сакланырга мәҗбүр булалар. Нәҗметдинев—Сайгин партиясендә дә нак шул хәл булды. Аклар ат биреп ладья алуга ирештеләр һәм позиция ягыннан начар хәлдә калдылар. Нәҗметдинев ферзен бирергә мәҗбүр булды. Аның ике ладьясы фактта актив уенга кертелә алмадылар. Нәтиҗәдә аклар үзләре көч-хәл белән ничьяга ирешергә тиеш булдылар.

Колчурин бик матур итеп Щербаковны отты. Кильматов Нотариуска бирелде, Хенкин белән Ермолин арасындагы партия ничья белән тәмамланды һәм Виноградов—Вельтмандер партиясе тигез хәлдә кичектерелде.

8 турдан соң Сайгинның 5,5 (7 партиядән), Хенкинның 4,5 (6 партиядән) һәм Нәҗметдиневнең 5,5 (8 партиядән) очколары бар.

6 нчы мартта 9 нчы турда Сайгин Кильматов белән, Хенкин Нотариус белән һәм Нәҗметдинев Косолапов белән очрашалар.

Х.

2 НЧЕ ТЕГҮ ФАБРИКАСЫНДА

Казанның 2 нче тегү фабрикасы коллективы 8 нче Март көнен лаеклы рәвештә каршылый. Фабрика февраль аеның производство планын арттырып үтәде. Алдынгы стахановчылардан А. И. Козловская, Лаврухина, Лысова, Медведева, Данилова һәм башкалар көнлек нормаларны системалы рәвештә арттырып үтәп киләләр.

Фабриканың цехларында Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне—8 нче Март турында беседалар үткәрелә. Цехларда социалистик ярыш договорларының үтәлеше тикшерелә. Хатын-кызлардан 60 кеше „ПВХО“ һәм „ГСО“ значокларына нормалар тапшыруга хәзерләнәләр.

6 нчы мартта көндез Зур Театр бинасында 1 нче һәм 2 нче тегү фабрикаларының коллективлары тантаналы җыелыш үткәрәләр. 8 нче Март көне турында докладтан соң спектакль була. Тамашага „Бакчалар чәчәк ата“ дигән пьеса куелачак. Производство планнарын арттырып үтәүче алдынгы стахановчылар бүләкләнәчәкләр.

Н. Г. Чернышевскийга памятник проекты төзү конкурсы тәмам булды. Беренче премия (10 мең сум) профессорлардан скульптор В. Лишевка һәм архитектор В. Яковлевка бирергә билгеләнде. Памятник Ленинградның Чернышевский мәйданына куелачак. РӘСЕМДӘ: Н. Г. Чернышевскийга В. Лишев һәм В. Яковлев иптәшләр эшләгән памятник проекты моделе.

Э. Ханкин һәм М. Редкин фотосы. (ТАСС фото-клишесе).

8 НЧЕ МАРТ ХӨРМӘТЕНӘ СТАХАНОВЧЫЛЫК ВАХТАЛАРЫ

3 нче мех фабрикасының кин куллану товарлары цехы февраль планын 107 процент итеп үтәде.

Эшчеләр һәм эшче хатын-кызлар февраль аендагы эш нәтиҗәләренә җыелышта йомгак ясап, Халыкара Коммунистик Хатын-Кызлар Көне хөрмәтенә 3 нче марттан 8 енә кадәр стахановчылык вахтасына басарга карар бирделәр һәм беренче квартал планын срогыннан элек үтәргә йөкләмә алдылар.

Цех коллективы производство планын көн саен 120—130 процент итеп үти. Отделкачы Зарипова, төзәтүче Зиннәтуллина һәм Гарифуллина, скорнякче Зиновьева иптәшләр көн саен ике норма үтиләр.

ТОРФ ЧЫГАРУ

Татстройматпромсоюз артельләре быел Столбище һәм Чаллы районнарында торф чыгаруны оештыруга хәзерләнәләр. Иң беренче чиратта 1.500 тонна торф чыгарылачак. Аннары торф чыгару ел саен 10.000 тоннага житкереләчәк. Бу районнарда 20—25 елга житәрлек торф запасы бар. Бу торфтан „Заря востока“ һәм „Волгапром“ заводларында кирпеч яндыру өчен файдаланылачак.

Сарык асраудан 75 мең сум доход

Азнакай районының Энгельс исемендәге колхозы үткән елны акчалата 195.682 сум доход алды. Шуның 75 мең сумын сарык фермасы бирде. Биредә үткән елны һәр сарыктан уртача 4 килограмм йон кыркып алдылар.

С. Хафизов.

ДРУЖИНАЧЫЛАРНЫҢ ХӘРБИ ПОХОДЫ

Сталин районының РОКК Комитеты күптән түгел санитария дружиначыларының противогазларда хәрби походын үткәрде. Походчылар Казаннан 5 километр ераклыктагы Кокушкино поселкысына бардылар. Алар анда 1 нче номерлы совхозда РОКК ның башлангыч оешмасын оештырдылар, РОКК членнарының җыелышын үткәрделәр.

Походта 25 дружиначы катнашты.

АЛДЫНГЫ КОЛХОЗ-СОВХОЗ ТЕАТРЫ

6 нчы Колхоз-Совхоз театры үзенең бердәм иҗад ансамбле булуы белән Татарстанның көчле профессиональ театрларның берсе булып тора. Сәнгать Эшләре Идарәсе тарафыннан Колхоз-Совхоз театрларының иҗад юлларын тикшерү өчен җибәрелгән комиссия бу театрга бәя биргәндә, „6 нчы Колхоз-Совхоз театры актерлар көче ягыннан, башка театрларга караганда, тагын да көчлерәк бер театр булып тора. Бу театрны, берничә яш уйнаучыларны алмаганда, тәмамланган профессиональ театр дип атап була“ дип әйтеп үтә. Дөрестән дә, бу театр үзендәге иҗад көчләре белән мактана ала. Аның составында озак еллар сәхнәдә уйнап, артистлык практикасы алган, яңа образлар тудыруда тырышып эшләүче карт артистлардан Исмагыйлев, Рәхмәтуллина, Мөхеттинов, Кольмәмәт кебек, театр белеме алган һәм озак еллар сәхнәдә эшләп, хәзерге көндә профессиональ көчләр булып әверелгән Галиуллина, Гыйматов, Хисаметтинов, Җәббарова, Сәгыйтев кебек көчләр—сәнгать мастерлары бар. Шулай ук күптән түгел театр мәктәбен тәмамлап, иҗад эшендә күренекле урын алган һәм төп рольләрне уңышлы башкарып килә торган Минкина, Нургалиев, Хәлиуллиналар да һәм үзешчән түгәрәктән күтәрелеп, хәзер профессиональ театрда эшләүгә күтәрелгән А. Әхмәтҗанова, Г. Әхмәтҗанова, Котов, Нигмәтуллин, Камаловлар да театрның күренекле көчләре булып саналалар.

Бу коллектив колхозларда спектакльләр кую белән генә чикләнми, бәлки җәмагат эшләре дә алып бара. Мәсәлән, 1939 нчы елда гына да күп кенә оештыру эшләре башкарды. В. И. Ленинне искә алу, Кызыл Армия көне, язгы чәчү, сабантуй, урыпҗыю, җирле Советларга сайлаулар уңае белән колхоз стахановчылары, ударниклары өчен кыр станнарында, сайлау участкыларында, колхоз клубларында, махсус программа белән, 45 түләүсез концерт оештырды. Төрле кампанияләргә карата җирле материаллар белән тулган 25 стена газетасы чыгарды. Коллектив үзешчән түгәрәкләргә системалы рәвештә ярдәм күрсәтә. Болардан тыш, тамашачыларның 17 тапкыр конференциясе уздырылды.

1939 нчы елны театр коллективы тамашачыларга „Шәмсекамәр“, „Яш йөрәкләр“, „Урманда“ исемле өч әсәрне күрсәтеп, 14 районда барлыгы 195 спектакль бирде һәм 75.500 тамашачыга культура хезмәте күрсәтте. Театр еллык планны 109 процент итеп үтәде.

1940 нчы елда коллектив яңадан-яңа уңышларга ирешү, тагын да яхшы эш үрнәкләре күрсәтү, колхозчы массаларга югары сыйфатлы спектакльләр бирү, идея ягыннан тирән, художество ягыннан көчле спектакльләр тудыру өчен көрәш алып бара һәм ул бу көрәштә тагын да зур уңышларга ирешер.

Әсгат Мәҗитев.

Театр директоры һәм художество эшләре житәкчесе.

Республикабызның фән работниклары

ПРОФЕССОР МИРОПОЛЬСКИЙ

Дәүләт университетының геология факультеты профессоры, геология фәннәре докторы Леонид Михайлович Миропольский үзенең фәнни хезмәтләре һәм укытучылык эше белән Татарстанда, шулай ук бөтен Советлар Союзында да зур авторитет белән файдалана торган фән эшлеклеләренең берсе. Аның тудырган 20 дән артык хезмәте фән хәзинәсендә һәм социалистик төзелештә гаять зур урын тоталар. Профессор Миропольский китаплар язу, университетта укыту эше белән бергә, фәнни тикшеренү эшендә дә зур тырышлык һәм энтузиазм белән эшләп килә.

Профессор Миропольскийның эш кабинетын, һәр вакытта дип әйтерлек, тикшеренү лабораториясе хәлендә күрергә туры килә. Зур-зур шкафларда том-том китаплар, Советлар Союзында һәм чит илләрдә чыгарыла торган фәнни журналлар өелеп торалар. Үзенең эш өстәле янында, микраскоп алдында профессор Миропольский утыра, ул, вакыт белән исәпләшеп тормастан, нәрсәнедер җентекләп өйрәнә, анализлар ясый. Аның алдында төрле кислоталар белән тулган пробиркалар, спертовкалар, кәгаз савытта ак төстәге минераль тора. Бу минераль—профессор Миропольский тарафыннан Чебоксар шәһәре тирәсендә табылган яңа минераль: хризотиль-азбест. Бу минераль профессор Миропольский тарафыннан 1939 нчы елда табыла. Бу минеральны ачу Татарстан һәм Чувашстан республикаларының халык хуҗалыгы төзелешенә аеруча зур файда китерәчәк, чөнки бу минераль, утка чыдаучан материал буларак, төзелеш өчен гаять кирәкле. Татарстан, Чувашстан территорияләрендә ул минераль яткан урыннар күп.

Профессор Миропольский хәзер Чебаксар районы гидроузласындагы Татарский ярусының литологиясен өйрәнү өстендә дә эшли. Бу проблеманы өйрәнү һәм хәл кылу Куйбышев гидроузелын төзүдә әһәмиятле бер чара булып тора.

Шулай ук ул, СССР фәннәр Академиясенең кушуы буенча, Татарстан һәм Чувашстан республикалары территорияләрендәге җир байлыкларын өйрәнү өстендә дә эшли.

Профессор Миропольский үсеп килә торган яш галимнәргә һәр вакытта якыннан торып практик ярдәм күрсәтә. Аннан укып чыккан күп кенә яш галимнәр фәнни тикшеренү эшендә зур гына уңышларга ирештеләр. Иптәш Миропольский житәкчелегендә яш фәнни работниклардан доцент Полянин, Ишмаев, Руденко һәм аспирант Алексеева иптәшләр фәнни тикшеренү эшләре алып баралар.

Профессор Миропольский фәнни тикшеренү һәм укытучылык эше белән генә чикләнми, ул Маркс—Энгельс—Ленин—Сталинның әсәрләрен, гомумән, марксизм таглиматын тирән мәхәббәт һәм тырышлык белән өйрәнә.

1938 нче елның маенда, профессор Миропольский югары мәктәп работникларының Бөтенсоюз киңәшмәсендә Казан Дәүләт университеты вәкиле булып катнашты. Ул үзенең Москва тәэсирләре турында болай ди: „Партия һәм хөкүмәт житәкчеләре белән Кремльдә очрашу минем хәтеремдә мәңге сакланыр. Бу очрашу вакытында мин бөек Сталинны күрдем, аның сөйләвен тыңладым. Бу очрашу минем рухымны тагын да күтәрде. Мин социалистик төзелешкә бөтен белемемне, ә кирәк булса, тормышымны да бирермен“.

Д. Иртуганов

ТАТАРСТАНДА

— Шушы елның беренче кварталында Татарстан Азык Промышленносте Халык Комиссариатының предприятиеләре 1926—27 нче елгы бәя белән 6 миллион 538 мең сумлык продукция эшләп чыгаралар.

— Терлекләрен һәм башка милекләрен иректе рәвештә страховать итүчеләргә Татстрах органнары узган ел 6 миллион 900 мең сум страхование акчасы түләгәннәр. Тормышларын коллектив рәвештә страховать итүчеләрнең семьяларенә 2 миллион сум түләнгән.

— РОКК ның Сталин район комитеты 1940 нчы елның 1 нче январеннан шушы көнгә кадәр 400 кешене „ГСО“ значкисты итеп хәзерләп чыгарды. Шулардан 28 кеше „ГСО“ ның икенче баскысына норма тапшырдылар.

— Чистай районының Булдырь авылы янында нефть эзләү дәвам итә. Андагы 1 нче номерлы скважина 961 метр тирәнлеккә кадәр бораулаган иде. Соңгы көннәрдә 2 нче номерлы скважинаны бораулау башланды.

— Шушы көннәрдә Сталин район советының башкарма комитеты президиумы җәйге сезонга хәзерлек турында райондагы йорт идарәләре председательләренең киңәшмәсен үткәрде. Киңәшмәдә йорт идарәләре председательләренең информацияләре тыңланды.

— Казан шәһәре ял йортында 1939 нчы елны 12 көнлек путевкалар белән барлыгы 4.364 кеше ял итте. 1940 нчы елда путевкалар 11 көнлек булачак һәм узган елгы 27 смена урнына 29 смена ял итәчәк. Ял йортына капитальный ремонт ясау өчен 16.000 сум акча җибәрелде.

— Быел Крутовка, Борисково һәм Кокушкино эшче поселкыларындагы водопровод башняләрен һәм насос станцияләрен җиһазлау эшләренә 90.000 сум акча тотылачак.

КӨНДӘЛЕК ВАКЫЙГАЛӘР

Бәхетсезлеккә очрау. 15 яшьлек Г. Мәһдиев дигән малай Ягодный бистәсенең Гладилов урамында конькида шуган вакытта бер йөкченең чанасы артына тотынып бара башлаган. Шул арада 31—05 нче номерлы автомобиль килеп житеп аны таптаган. Мәһдиевне авыр хәлдә больницага җибәргәннәр.

Җаваплы редактор Һ. АБДРАХМАНОВ.

Ответ. редактор Х. АБДРАХМАНОВ.

Москвадан килгән инженерлар өчен, төрле срокларга Бауман районында

БҮЛМӘЛӘР КИРӘК

Түләү килешү буенча, Бауман урамы, 70 адресы янсә 44—05 телефоны буенча теләсә нинди вакытта Новацкийгә мөрәҗәгать итәргә. 387—2—1

РСФСР Сәүдә Халык Комиссариатының Казандагы өлкәара базасы „РОССНАБТОРГ“ 1940 нчы ел, 1 нче январьдан „РОСЗАГОТСНАБТОРГ“ дип яңадан исемләнде. 240—3—3

Завод хезмәткәрләрен һәм эшчеләрен урнаштыру өчен 5—6 ай срок белән квартиралар, бүлмәләр һәм почмак урыннар КИРӘК

Казан, Островский урамы, 8, 16 нчы квартира. Ял көннәреннән башка һәр көн көндез 10 сәгаттән 3 кә кадәр, Ф. Г. Асафовка мөрәҗәгать итәргә. 384—3—3

ТАТНАРКОМЛЕС

Чернышевский урамындагы 2 нче йорттан Толстой (элекке Подлужный) урамындагы 41 нче йортка, Сал Агызу һәм Урман эшләре институты бинасына КҮЧЕРЕЛДЕ. 374—2—1

ТАТАР ДӘҮЛӘТ ОПЕРА ТЕАТРЫ

Зур Драма театры бинасында 7 нче мартта (Талон 83)

ЗУР КОНЦЕРТ

Кич 9 сәгатьтә башлана.

9 нчы мартта Татар Дәүләт Академия театры бинасында

ИРЕК

Талон 84.

Кич 7 сәгать 30 минутта башлана.

Коллектив рәвештә килү өчен 29—04 телефоны буенча заявкалар алына.

ЗУР ДРАМА ТЕАТРЫ

Бүген, 5 нче мартта, шулай ук 6 нчы мартта көндез һәм 8, 9 нчы мартта

ЛЕНИН

6 нчы мартта кич

БАКЧАЛАР ЧӘЧӘК АТА

Талоннар: бүген 116. Иртәгә көндез талоннар белән кертелми, кич 117.

Коллектив рәвештә килү өчен заявкалар алына. Спектакльләр кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Билетлар көндез 11 сәгать 30 минуттан 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 7 сәгать 30 минутка кадәр кассада сатыла.

Киров районындагы КУЛЬТУРА САРАЕНДА

Татар Дәүләт Опера театры постановкалары 5 һәм 6 нчы мартта

Файдасызга саклану

Талоннар: 5 нче мартта 62, 63 һәм 6 нчы мартта 64, 65.

Кич 8 дә башлана.

Галиәсгар Камал исемендәге Татар Дәүләт Академия театры

Бүген, 5 нче мартта, шулай ук 6 нчы мартта көндез 12 сәгатьтә һәм кич

ШӘМСЕКАМӘР

Талоннар: бүген 127, иртәгә көндез 128, кич 129. Спектакль кич 7 сәгать 30 минутта башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 2 гә һәм кич 5 сәгатьтән 9 га кадәр ачык. ТДАТ.

ДӘҮЛӘТ ЦИРКЫ

Бүген, 5 нче мартта, данлыклы ЗОЛЛО ТИМЕР ЮЛЫ

300 хәйван һәм кошлар катнаша һәм башка күп номерлар.

РСФСР ның атказанган артисты һәм орденлы М. ЗОЛЛОның соңгы гастрольләренә билетлар сатыла.

6 нчы мартта көндез 12 сәгатьтә зур программа буенча КӨНДЕЗГЕ ЦИРК УЕНЫ

Уен кич 8 дә башлана. Касса һәр көн көндез 11 сәгатьтән 3 кә һәм кич 5 тән 9 га кадәр ачык.

БҮГЕН КИНОЛАРДА

„ЭЛЕКТРО“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ЯШӘРГӘ
„УНИОН“ 12, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	ДУСЛАР
„КЫЗЫЛ ЙОЛДЫЗ“ 6, 8 һәм 10 да	ПАТРИОТ
„ЧАТКЫ“ 6, 8, 9—30 да.	ДОШМАН ИШЕК ТӨБЕНДӘ
„ПИОНЕР“ 11, 1, 2, 4, 6, 8 һәм 10 да.	БЕТХОВЕН КОНЦЕРТЫ Көндез 1 сәгатьтә мәктәпкә кадәр яштәге балалар өчен сеанс.
„Колхозник“ 6, 8 һәм 10 да.	УКЫТУЧЫ
„РОТ-ФРОНТ“ 6, 8, 10 да.	ИНЖЕНЕР КОЧИННЫҢ ЯЛГЫШУЫ
КУЛЬТУРА САРАЕ 4-30, 7, 9 да.	МИНИН ҺӘМ ПОЖАРСКИЙ

КИРӘК:

Казан Психатрия больницасына даими эшкә ХИСАПЧЫЛАР, МАШИНИСТКАЛАР, ОХРАННИКЛАР, ДИПЛОМЛЫ КОЧЕГАРЛАР, СЛЕСАРЬ-МЕХАНИКА ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА НОРМАЛАУЧЫЛАР һәм ТӨЗЕЛЕШ ЭШЛӘРЕ БУЕНЧА ӨЛКӘН БУХГАЛТЕР. Казан, Ершов кыры, 5 (3, 6 һәм 8 нче маршрут трамвайлары). Телефоннар: 4—27 һәм 32. 337—3—1

Татнаркомхозның Мелиорация-Гидротехника конторасына ИНЖЕНЕРЛАРДАН: ГИДРОТЕХНИКЛАР, ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОГЕОЛОГЛАР. ТЕХНИКЛАРДАН: ТӨЗҮЧЕЛӘР, ГИДРОТЕХНИК-ИНВЕНТАРИЗАТОРЛАР, САНТЕХНИКЛАР, КОЛЛЕКТОРЛАР, БОРАУЛАУ МАСТЕРЛАРЫ. Шунда ук ЯРДӘМЧЕ ЭШЧЕЛӘР. Казан, Кремль, 3 нче подъезд. 330—5—4

УПОЛН. ГЛАВЛИТА ТАССР. № А — 260 ТИПОГРАФИЯ ИМЕНИ АЛЕКСАНДРОВА, ДОМ ПЕЧАТИ 1940 ГОД. ЗАКАЗ № 890.